«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле
гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

Килешенде:

Өлкән тәрбияче
_________ Хөснетдинова Д.Р.
«_31_» ___08___ 2022 ел

Раслыйм:
«Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы»
МБМББ житәкчесе :
_________ Габидуллина Э.С.
«_31_» ___08___ 2022 ел

# 6 нчы зурлар (5- 6 яшь)
# төркеменең
# 2022-2023 нче уку елына
# эш программасы

Төзеде:
Гарипова Сания Наил кызы
Миннегулова Луза Мирхан кызы

Яр Чаллы
2022 ел

**Эчтәлек**

1.Максатлар бүлеге 3
1.1.«Гөлназ» 49 нчы балалар бакчасы турында гомуми белешмә 4
1.2. Төркем турында белешмә. 4
1.3. Программаның максатлары һәм бурычлары 4
1.4. Программага хас үзенчәлекләр 5
1.5. Зурлар төркеме эшчәнлегенең юнәлеше 8

2.Эчтәлек бүлеге 8
2.1.Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары 8
2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларны үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге 8
2.3. Психологик-педагогик эш эчтәлеге
2.3.1. «Социаль-коммуникатив үсеш» белем бирү өлкәсе 9
2.3.2. «Танып-белү үсеше» белем бирү өлкәс 25
2.3.3. «Сөйләм үсеше» белем бирү өлкәсе 32
2.3.4. «Сәнгати-эстетик үсеш» белем бирү өлкәсе 40
2.3.5. «Физик үсеш» белем бирү өлкәсе 52
2.4. Ата-аналар белән эш 58

3.Оештыру бүлеге 60
3.1. Көндәлек режим 60
3.2. Методик программа белән тәэмин ителеш 61
3.3. Предметлы тирәлек мохите оештыру үзенчәлекләре 62
3.4. Материаль-техник тәэмин ителеш 65

Кушымта
Кушымта 1. Балаларның яшь үзенчәлекләре 66
Кушымта 2. Белем бирү эшчәнлегенең тематикасы 68
Кушымта 3. Белем бирү эшчәнлеге челтәре 74
Кушымта 4. Сәламәтләндерү чаралары 75
Кушымта 5. Милли–җирле компонент (ЭРС, УМК) 78

## 1. Максатлар бүлеге

Бу программа ФДББСна нигезләнеп эшләнгән Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге «Туганнан алып мәктәпкәчә» төп белем бирү программасына һәм балалар бакчасының төп гомуми белем бирү программасынатаянып төзелде.

**Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелде:**

1. Федеральный закон от 29.12.2012 №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»с изменениями и дополнениями от 14.07.2022 №298, №299, №300
2. Федеральный закон от 03.08.2018 №317-ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федерального закона «Об образовании в Российской Федерации»;
3. Комментарии к ФГОС дошкольного образования Минобрнауки России, Департамента общего образования от 28.02.2014 г. №08-249;
4. Профессиональным стандартом "Педагог (педагогическая деятельность в сфере дошкольного, начального, основного и среднего общего образования) (воспитатель, учитель)", утвержденного приказом Минтруда и Соцзащиты РФ № 544н от 18 октября 2013 г. (с изм. на 5.08.2016г);
5. СанПиН 2.4.3648-20 от 28 сентября 2020 г «Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодёжи»;
6. СанПиН 2.3/2.4.3590-20 "Санитарно-эпидемиологические требования к организации общественного питания населения" от 27 октября 2020 г. № 32;
7. СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или) безвредности для человека факторов среды обитания» от 28.01.2021 № 2;
8. Санитарно-эпидемиологические правила СП 3.1/2.4.3598-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации работы образовательных организаций и других объектов социальной инфраструктуры для детей и молодежи в условиях распространения новой короновирусной инфекции (COVID-19)», утвержденный постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 30 июня 2020 года №16.
9. Приказ Министерства просвещения РФ от 31.08.2020г. № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления деятельности по ООП – образовательным программам ДО»;
10. Методическими рекомендациями Минобрнауки «О разработке основной общеобразовательной программы дошкольного образования» от 21 октября 2010 года, № 03-248;
11. Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан» от 08.07.1992 №1560-XII (изменения и дополнения от 27.04.2017 г. №27-ЗРТ);
12. Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013 г. №68-ЗРТ (принят Государственным Советом 28.06.2013 г.);
13. Устав муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения города Набережные Челны «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по познавательно-речевому направлению развития детей № 49 «Гульназ», постановление от 22 сентября 2017 г. № 5633;
14. Примерная общеобразовательная программа дошкольного образования «От рождения до школы» под редакцией Н.Е.Вераксы, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой, 2020 г.
15. «Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 49 «Гульназ», приказ № 192 от 31 августа 2020 года.

## 1.1.Гомуми белешмә

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының атамасы:**

«Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү оешмасы.

**Кыскача атамасы:** «Гөлназ» 49нчы балалар бакчасы МБМББУ.

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының адресы:**

*субъект РФ:*Татарстан Республикасы
*индекс*: 423828
*торак пункты:* Яр Чаллы шәһәре
*урам:Шамил Усманов*
*йорт: 133*
*шәһәрнең федераль телефон коды:* (8552) *телефон:* 42-65-92
*факс:* 42-65-92 *e-mail*: det.sad49@mail.ru
сайт: https://edu.tatar.ru/n_chelny/page92698.htm

**Мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү оешмасының җитәкчесе:**

Габидуллина Эльза Сагил кызы

**Балалар бакчасы эшчәнлегенең юнәлеше:**

1.Танып белү-сөйләм үсеше, социаль-шәхси үсеш, физик үсеш, нәфис-нәфәсәти үсеш.
2.Мәктәптә укырга әзерләү (логик фикерләү, уку грамотасы...)
3.Сәламәтләндерү һәм авырулардан профилактика чаралары.

Балалар бакчасы 5 көнлек эш атнасында 6.00-18.00 сәгатькә кадәр эшли.

## 1.2. Төркем турында белешмә

### Төркемнең составы

| № гр | яше | Саны | Малайлар | Кызлар |
|---|---|---|---|---|
| 6 | 5-6 | 18 | 6 | 12 |

Балаларның танып-белү эшчәнлеген үстерү, тәрбия һәм белем бирү процессының сыйфатын яхшырту максатында балалар бакчасы үз алдына түбәндәге бурычларны куя:

1. Балаларның һәрьяклап үсешен тәэмин итү юнәлешендә яңа технологияләрне, үрнәк тәҗрибәләрне киң кулланып, балаларның сәламәтлеген саклау, аларны физик яктан ныгыту буенча нәтиҗәле эш алып баруны дәвам итү.

2. Балаларга тәрбия һәм белем бирү сыйфатын камилләштерү максатыннан чыгып, федераль дәүләт белем бирү стандартларына (ФДББС) таянып, алдынгы педагогик тәҗрибәләргә нигезләнеп, педагогларның һөнәри осталыгын үстерү һәм тәрбия-өйрәтү процессында информацион-компьютер технологияләрен куллану.

3.Балалар бакчасында бала шәхесен формалаштыруда гаилә белән бердәм эшчәнлек алып бару. Балалар бакчасы һәм гаилә арасындагы элемтәне халык педагогикасына, алдынгы гаилә тәҗрибәсенә таянып ныгыту, милли рухта мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтү.

4. «Татарстан Республикасы халыклары телләре» турындагы законны тормышка ашыруда яңа алымнарны куллану һәм укыту-методик комплекты аша балаларның сөйләмен камилллэштерүне дәвам итү.

Балаларга белем һәм тәрбия бирү өчен түбәндәге кабинетлар эшләп килә: татар теле кабинеты, музыка һәм физкультура залы.

## 1.3 Программаның төп максатлары һәм бурычлары

**Программаның төп максатлары**-мәктәпкәчә яшьтәге баланың тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңай шартлар тудыру, шәхеснең база культурасы нигезләрен формалаштыру, шәхси һәм яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, психик һәм физик сыйфатларны һәрьяклап

үстерү, хәзерге җәмгыятьтәгетормышка әзерләү, уку эшщчәнлегенә алшартлар формалаштыру, мәктәпкәчә яшьтәге баланың тормыш иминлеген тәэмин итү. Программада баланың шәхесен үстерүгә, балалоарның сәламәтлеген ныгытуга һәм саклауга, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балаларда патриотизм, актив тормыш позициясе, тормышта килеп туган төрле хәлләрдән чыгу юлларын баба белү, традицион кыйммәтләргә карата хөрмәт кебек сыйфатлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирелә. Бу максатлар бала эшчәнлегенең төрле төрләре: уен, аралашу, хезмәт, танып-белү-тикшеренү, продуктив (рәсем ясау, конструктив һ.б.), музыка белән шөгыльләнү, уку процессларында тормышка ашырыла.

**Бурычлар:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру.

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче дәрәҗә ия:

- һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;
- төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергәярдәм итәрлек кешелеклде һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен максималь файдалану, тәрбия-белем бирү процессының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында аларны интеграцияләү;
- тәрбия-белембирүпроцессыниҗадиоештыру;
- белем бирү материалын куллануның вариативлыгы, һәрбер баланың кызыксынулары һәм сәләтләренә туры китереп иҗат эшен үстерергә мөмкинлек бирү;
- балалар иҗаты нәтиҗәләренә хөрмәт белән карау;
- мәктәпкәчәбелембирү учреждениесеһәмгаиләшартларында балалар тәрбияләүгә бердәм якын килү;
- балалар бакчасы һәм башлавнгыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирү эчтәлегендә акыл һәм физик яктан көч килүләрне булдырмаучы, предметлы укыту басымы ясамауны тәэмин итүче дәвамчанлыкны үтәү;
- региональякынкилүнегамәлгәашыру.

## 1.4 Программага хас үзенчәлекләр

***Бала шәхесен үстерүгә юнәлгәнлек***

Программаның өстенлеге — ирекле, үз-үзенә ышанган, актив тормыш позициясенә ия, тормыштагы төрле хәлләрдән чыгу юлларын табуга иҗади килергә омтылган, үз фикере булган һәм аны яклый белә торган кеше тәрбияләү.

***Программаның патриотик юнәлгәнлеге***

Программада балаларда Туган илгә карата мәхәббәт, патриотик хисләр, Ватанның казанышлары белән горурлану, Россиянең героик үткәне һәм бәхетле киләчәге булган күпмилләтле бөек ил икәнлегенә ышаныч тәрбияләүгә зур игътибар бирелә.

***Әхлакый тәрбиягә, традицион кыйммәтләрне яклауга юнәлгәнлек***

Ата-анага мәхәббәт, өлкәннәргә ихтирам, кечкенәләргә, олы яшьтәге кешеләргә карата кайгыртучан мөнәсәбәт кебек традицион кыйммәтләргә хөрмәт тәрбияләү; традицион гендер күзаллаулары булдыру; балаларның үз гамәлләрендә уңай үрнәккә иярү омтылышын тәрбияләү. Алга таба укуны дәвам итү максатын кую Программа балаларда танып белү кызыксынучанлыгын үстерүгә, белем алу омтылышына, алга таба бөтен тормышы буена укуга (мәктәптә, институтта һ.б.) карата уңай мотивациягә; барлык кешеләргә дә белем

алырга кирәклекне аңлауга юнәлтелгән. Белем алуга карата аны иң мөһим тормыш кыйммәтләренең берсе итеп карауны формалаштыру.

***Балаларның сәламәтлеген саклауга һәм ныгытуга юнәлгәнлек***

Программа тәрбиячеләр алдына куя торган төп бурычларның берсе — балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларда сәламәт яшәү рәвеше турында элементар күзаллаулар булдыру, уңай гадәтләр, шул исәптән дөрес туклану гадәте, хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ тәрбияләү.

***Баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алуга юнәлгәнлек***

Программа һәрбер баланың эмоциональ иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән, аңа исә тормыш эшчәнлеген оештыру мәсьәләләрендә дә (көндәлек режимны баланың индивидуаль үзенчәлекләренә якынайту һ.б.), бала белән үзара аралашу формаларында һәм ысулларында да (аның индивидуальлегенә карата хөрмәт, эмоциональ халәтләренә игътибарлылык, үз-үзенә ихтирамлылык хисләрен яклау һ.б. ш.) балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу хисабына ирешелә.

***Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән үзара бәйләнеш***

Программа гаиләнең уникаль тәрбия институты буларак кыйммәтен һәм тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән җаваплы һәм тыгыз мөнәсәбәтләр булдыру кирәклеген ассызыклый. «Балалар бакчасының гаилә белән багланышы» бүлегендә тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары белән төп эшләү формалары тасвирлана, аларны куллану педагогларга мәктәпкәчә белем бирүнең гомуми мәгариф программасын уңышлы гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә. Бала белән өйдә шөгыльләнү өчен кулланмалар — «Җиде Гном мәктәбе» сериясеннән китаплар белән тәэмин ителү Программаның мөһим өстенлеге булып тора.

**Программаны үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**
**Максат ориентирлары**

Мәктәпкәчә балачакның үзгәлеге (бала үсешенең сыгылмалылыгы, аның үсеш вариантларының төрлелеге, аның табигыйлеге һәм нәрсәгә дә булса бәйле булуы) мәктәпкәчә яшьтәге баладан конкрет белем бирү нәтиҗәләренә ирешүне таләп итәргә мөмкинлек бирми һәм мәгариф программасын үзләштерү нәтиҗәләрен максат ориентирлары рәвешендә билгеләү зарурлыгын шарт итеп куя. Мәктәпкәчә белем бирүнең ФДББСнда күрсәтелгән максат ориентирларын баланың ирешергә мөмкин булган казанышларының социаль-норматив сыйфатламалары буларак карарга кирәк. Бу — педагоглар һәм ата-аналар өчен өлкәннәрнең тәрбия эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүче ориентир.

**Программаны үзләштерүнең нәтиҗәләрен бәяләү системасы**

МББ ФДББС белән ярашлы рәвештә максат ориентирлары турыдан-туры, шул исәптән педагогик диагностика (мониторинг) рәвешендә дә, бәяләүгә алынмый һәм аларны балаларның реаль казанышлары белән формаль чагыштыру өчен нигез була алмый. Алар балаларның әзерлегенә һәм белем бирү эшчәнлегенә карата кабул ителгән таләпләргә туры килә торган объектив бәяләмәнең асылы булып тормый. Программаны үзләштерү арадаш аттестацияләр һәм тәрбияләнүчеләрнең йомгаклау аттестациясен уздыру белән кушылып китми.

Әмма педагог үз эше барышында һәрбер баланың индивидуаль үсеш траекториясен булдырырга тиеш. Моның өчен педагогка үз эшен бәяләүнең балалар белән иң уңайлы рәвештә үзара бәйләнеш булдырырга ярдәм итүче инструментарие кирәк.

Беренче чиратта, игътибарны әкренләп объектив (тестлар уздыру) якын килүдән аутентик бәяләү ягына күчерү турында сүз бара. Тамырлары белән стандартлаштырылган тест традицияләренә китеп, объектив якын килү кысаларында тикшеренүләр махсус

бурычларны хәл итү барышында балалардагы аерымлыкларны (еш кына җитешсезлекләрне) билгеләүгә юнәлтелгән иде. Әлеге тестлар килеп чыккан нәтиҗәләрне норма белән чагыштырырга мөмкинлек тудыра, шуның белән һәрбер баланың үз яшьтәшләре белән чагыштырганда үсеше турында мәгълүмат бирә. Шунлыктан мондый тестлар педагогик хәвефлелек төркеменә керергә тиешле балаларны ачыклауда киң кулланыла.

Әлеге ысулның төп җитешсезлеге шунда: ясалма биремнәр еш кына балаларның көндәлек тормышыннан шактый ерак, шуңа күрә алар мәктәпкәчә яшьтәге балаларның реаль мөмкинлекләрен тулысынча чагылдыра алмыйлар. Тест ысулы балаларның социаль даирәсе үзенчәлекләрен исәпкә алмый, һәм аның нәтиҗәләренә корылган фаразлар да шактый шартлы. Аутентик бәяләүнең нигезендә түбәндәге принциплар ята.

Беренчедән, асылда ул махсус биремнәрне үтәү нәтиҗәсенә түгел, баланың реаль тәртибен анализлауга карап корыла. Мәгълүмат турыдан-туры баланың тәртибен күзәтү ярдәмендә туплана. Күзәтү нәтиҗәләрен педагог гадәти тестларда куллана торган, мәктәпкәчә яшьтәге баланың реаль тормышына кагылышы аз булган уйлап чыгарылган ситуацияләрдә түгел, табигый мохиттә (уеннар вакытында, режим моментлары барышында, дәресләрдә) таба.

Икенчедән, әгәр тестларны махсус өйрәтелгән профессиональ белгечләр (психологлар, медицина хезмәткәрләре һ.б.) уздырса, аутентик бәяне исә бала белән озак вакыт булган, аның тәртибен яхшы белгән өлкәннәр куя ала. Бу очракта педагог тәҗрибәсе бәяләп бетергесез.

Өченчедән, аутентик бәя югары дәрәҗәдә структурлашкан.

Ниһаять, әгәр тестлар ярдәмендә бәя кую очрагында ата-аналар алынган мәгълүматларның мәгънәсен һәрвакытта да аңлап бетермәсәләр һәм шуңа да еш кына балаларга тест уздыруга тискәре мөнәсәбәт күрсәтсәләр, аутентик бәяләү вакытында җаваплар аларга аңлаешлы. Ата- аналар теге яисә бу сорауга җавап эзләгәндә педагогның партнерлары булып китәргә мөмкин.

**Педагогик диагностика**

Программаны гамәлгә ашыру балаларның индивидуаль үсешен бәяләүне күздә тота. Мондый бәяләү педагогик хезмәткәр тарафыннан педагогик диагностика (мәктәпкәчә яшьтәге балаларның индивидуаль үсешенә педагогик гамәлләрнең нәтиҗәлелеген бәяләү белән бәйле һәм аларны алга таба планлаштыруның нигезендә ятучы бәя бирү) кысаларында уздырыла. Педагогик диагностика балаларның гадәти һәм махсус оештырылган эшчәнлектә активлыгын күзәтү барышында үткәрелә. Педагогик диагностика өчен инструментарий — балалар үсешен күзәтү карталары, алар һәрбер баланың индивидуаль динамикасын һәм үсеш перспективаларын түбәндәгеләр барышында билгеләргә мөмкинлек бирә:

• яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашулар (контакт урнаштыру һәм аны дәвам итү, уртак карарлар кабул итү, каршылыкларны хәл итү, лидерлык һ.б. ысуллары ничек үзгәрә);
• уен эшчәнлеге;
• танып белү эшчәнлеге (балаларның сәләтләре, танып белү активлыгы үсеше ничек бара);
• проект эшчәнлеге (балаларның инициативалылыгы, җаваплылыгы һәм автономиясе үсеше ничек бара, үз эшчәнлеген планлаштыру һәм оештыру күнекмәсе ничек үсә);
• сәнгати эшчәнлек;
• физик эшчәнлек.

Педагогик диагностика нәтиҗәләре фәкать түбәндәге белем бирү бурычларын хәл итү өчен кулланыла ала:

1) белем бирүне индивидуальләштерү (шул исәптән балага булышлык күрсәтү, аның белем бирү траекториясен булдыру яисә аның үсеш үзенчәлекләренә профессиональ төзәтмә кертү);

2) балалар төркеме белән эшне оптимальләштерү. Белем бирү эшчәнлеге барышында балаларның индивидуаль динамикасын бәяләү һәм үз гамәлләренә төзәтмә кертү өчен педагоглар диагностик ситуацияләр булдырырга тиеш.

### 1.5 Зурлар төркеме эшчәнлегенең юнәлеше

Төркемдә белем бирү процессы комплекслы һәм яңа парциаль программалар кулланылып үткәрелә:

Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан алып мәктәпкәчә”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү комплекслы программасы.

Программа сөйләм телен үстерү бүлегеннән тыш тулы күләмдә кулланыла.

*Парциаль программа:*

Р.К.Шаехова. “Сөенеч - Радость познания” региональ мәктәпкәчә белем бирү программасы, (ФДБС туры китерелгән).

## 2. Эчтәлек бүлеге

### 2.1. Тәрбия һәм өйрәтү бурычлары

Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, аларның сыйфатлы физик үсешен тәэмин итү. Һәр баланың эмоциональ уңай халәтен саклауга булышу.

Үз вакытында гомуми хәрәкәтләр һәм кул хәрәкәтләре формалашуга, шуышырга һәм йөрергә өйрәнүгә ярдәм итү.

Баланың талчыгуын булдырмау.

Күрү һәм ишетү юнәлешләрен формалаштыру.

Сиземләү тәҗрибәсен баету.

Өлкән кешенең сүзләрен аңлау сәләтен үстерү һәм актив сөйләмгә ирешүгә әзерләү.

Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү процессына керешү омтылышларын хуплау.

Балаларның үзара татулыгына, якын кешеләренә карата аерым дустанә мөнәсәбәтенә булышлык итү.

Уенчыкларга, рәсемнәргә, музыкага, җырлауга карата кызыксыну уяту; баланың гади бию хәрәкәтләре башкарудагы активлыгына булышлык итү.

Һәр баланың үз яшенә туры килгән сәләтләрне үзләштерүенә актив ярдәм итү, алынган нәтиҗәләрне системалы рәвештә һәм дөрес анализлау.

### 2.2. 2 яшьтән алып мәктәп яшенә кадәрге балаларның үсеш юнәлешләренә туры килгән белем бирү эшчәнлеге

2–7 яшьлек балалар белән психологик-педагогик эш эчтәлеге «Социаль-коммуникатив үсеш», «Танып белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Сәнгати- эстетик үсеш», «Физик үсеш» белем бирү өлкәләре буенча бирелә. Эшнең эчтәлеге мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, аларның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен искә алып, төрле яклап үсешенә юнәлтелгән. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын формалаштыру буенча психологик-педагогик эш бурычлары белем бирүнең һәрбер өлкәсенең үзгәлеген чагылдыра торган бурычлар белән, мәҗбүри психологик тәэмин итү белән беррәттән, барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү барышында интеграцияле хәл ителә. Бу очракта программаның мәгариф бурычларын хәл итү турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге кысаларында гына түгел, режимлы моментлар барышында да — өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлегендә дә, мәктәпкәчә яшьтәгеләрнең мөстәкыйль эшчәнлегендә дә карала.

## 2.3 Белем өлкәләре буенча комплеклы - тематик план
## 2.3.1. «СОЦИАЛЬ-КОММУНИКАТИВ ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе

### *Социальләштерү*
### *Аңлатма язуы*

«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балалар бакчасында балаларның (кечкенәләр, үзеннән зурраклар, яшьтәшләре, малайлар-кызлар, төркемгә килгән «яңа» балалар белән) туган телдә аралаша белү күнекмәләрен үстерү.

Төрле эшчәнлек төрләрендә балаларга туган телдә үзара һәм өлкәннәр белән бай, эчтәлекле аралашу өчен шартлар тудыру.

Элементар әхлак кагыйдәләренә өйрәтү, әхлак буенча аралашу үрнәкләре бирү, сөйләмдә татар халык фольклорын (мәкальләр, әйтемнәр, юаткычлар һ. б.) куллануга теләк уяту.

Бөтен кешелек өчен уртак байлык булган патриотизм хисләренең әхлакый нигезен булдыру өчен шартлар тудыру (гаиләсенә, балалар бакчасына, туган ягына, иленә, әйләнә- тирә дәгел әргә мәхәббәт).

Гаиләң һәм аның тарихы турындагы күзаллауларны тирәнәйтү. Гаилә составы, туганнар (әти-әни, әби-бабай, абый-эне, апа-сеңел, туганнан туган абый-апалар), гаиләдәге урыны, туганлык җепләре һәм гаилә эчендә бәйләнешләр («Мин этигә - ул, ә әбигә - онык», «Газизә апа - минем Фатыйма әбиемнең кызы»), эти-өниләрнең һәм туганнарның һөнәр һәм шөгыльләре турында күзаллаулар булдыру; туганнарның фотографияләрен карап, баланың эти-әниләре һәм башка туганнары белән тышкы охшашлыгына басым ясау.

Үзенең уңыш һәм казанышларына, эти-әниләренең, якын кешеләренең, дусларының, Олимпия уеннары спортчыларының, артистларның халыкара конкурсларда яулаган уңыш һәм казанышларына шатлык, горурлык хисләре тәрбияләү.

Сюжетлы-рольле уеннар өчен темалар төрлелеген хуплау; әйләнә-тирәдән, татар язучылары һәм шагыйрьләренең әсәрләреннән, телетапшырулардан, шәһәр (авыл) буенча экскурсияләрдән, күргәзмәләрдән, походлардан алган белемнәргә нигезләнеп, сюжет үсешенә ярдәм итү.

Балаларның шартлы формада милли уенчыкларны, кулдан ясалган уенчыкларны файдаланган; тормышта булган хәлләрне, Идел буе халыклары әкиятләре сюжетларын, мультфильмнарны һ. б.ны чагылдырган шәхси һәм күмәк режиссерлык уеннарына булышлык күрсәтү.

Балаларның артистлык сәләтләрен үстерү, аларны сәхнә сәнгатенә тарту: концертлар кую, татар җырларын җырлау, Идел буе, халыклары биюләрен башкару, спектакльләрдән күренешләр күрсәтү. Яшьтәшләре, эти-әниләр һәм кунаклар алдында чыгыш ясарга мөмкинлекләр булдыру.

Инициативалылыкны, халык уеннары кагыйдәләрен үтәүне, тигез хокуклы партнёр позициясен ала белүне хуплау.

Белем өлкәсе "Социаль- шәхси үсеш" җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.

Планлаштыру интеграция принциплары, төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

| Аталышы | Белем һәм күнекмәләр | Методик алымнар |
|---|---|---|
| **Сентябрь** | | |
| **Балалар бакчасы** | Тәрбияче балаларны кабул итә,иртәнге гимнастика үткәрә, балалрны ашата, алар белән уйный. | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| **Транспорт** | Гаражда күптөрле эшләр өчен машиналар тора..Машина йөртүчеләр праваларын алалар, диспетчер эш бирә, бензин салалар, биремне үтиләр: автобус пассажирлар, ашыгыч ярдәм машинасы табипны чирлеләр янына йөртә, экскурсия автобуслары йөри һ.б. | |
| **Шәһәр буйлап сәяхәт** | Башка шәһәрдән экскурсиягә ял итүчеләр килгән. Экскурсовод аларга шәһәрне төрле урыннарын күрсәтә,сөйли. | |
| **Кибет** | Ашамлыклар кибетендә төрле бүлекләр бар. Бик күп сатучылар эшли, кассалар берничә. Сатып алучылар ризыклар белән кызыксыналар, сайлыйлар, сатып алалар. | |
| **Октябрь** | | |
| **Транспорт** | Урамнарда күптөрле хезмәт күрсәтүче машиналар йөриләр. Җәяүлеләр тротуардан йөриләр. Машиналар һәм җәяүлеләр юл йөрү кагыйдәләрен бозмыйлар. Машиналар махсус машиналарга юл бирәләр(ашыгыч ярдәм,,, янгын сүндерүче һ.б.). | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү |
| **Балалар бакчасы** | Тәрбияче иртәнге гимнастика үткәрә, балалар музыка шөгыленә киләләр: җырлыйлар, бииләр; уйныйлар | |

| | | |
|---|---|---|
| **Уенчыклар кибете** | Сатып алучылар уенчыклар сайлыйлар, сатучы белән киңәшләшәләр, кассага акча түлиләр, чекларын сатучыга бирәләр. Сатучы сатып алучылар белән ягымлы сөйләшә, аларга төрле уенчыклар тәкъдим итә, алар турында сөйли, уенчыкларны биреп җибәрә, сатып алынган әйберләр өчен рәхмәт әйтә. | |
| **Почта** | Кешеләр бер- берсенә хатлар язалар, телеграммалар, посылкалар җибәрәләр. Хат ташучы почтаны адреслар буенча тарата. | |
| | **Ноябрь** | |
| **Шифаханә** | Табиб кешеләрне дәвалый: тыңлый, кан басымын үлчи, тамагын карый, рецепт язып бирә. Шәфкать туташы укол ясый, бәйли. | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү, балаларның дуслык турында мәгълүматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәнен, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгын төшендерү. |
| **Төзүчеләр** | Төзүчеләр зур гараж җиткерәләр, анда күп машиналар торачак. | |
| **Транспорт** | Йөк һәм җиңел автомашиналар урам буйлап баралар, җәяүлеләр тротуар буйлап баралар, юл аша чыгалар, бар да юл кагыйдәләрен саклап йөриләр. | |
| **Кибет** | Төрле бүлекләр белән яңа супермаркет ачылган:савыт-саба, җиһаз, канцтоварлар һәм башкалар. Сатып алучылар товар сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар (төсе, материалы, әһәмияте) | |
| | **Декабрь** | |
| **Җәнлекләр шифаханәсе** | Кешеләр шифаханәгә авыру җәнлекләрне алып киләләр. Ветеринар авыру җәнлекләрне дәвалый: карый, җылыткыч куя, дарулар билгели, уколлар ясый. | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен ныгыту, һөнәрләрнең кирәк-яраклары турындагы белемнәрен үстерү, диалог корып сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү. Яңа ел бәйрәме турында белемнәрен ныгыту. |
| **Гаилә** | Яңа ел бәйрәме: чыршы сатып алу һәм аны бизәү, гаилә әгъзаларына бүләк әзерләү, котлаулар һәм бүләкләр белән Кыш бабайның килүе. | |

| | | |
|---|---|---|
| **Кыш бабайның остаханәсе** | Кыш бабай, чыршы бизәү очен уенчыклар әзерләү остаханәсе ачуны сорап, хат җибәргән. Кабул итүче килүчеләрдән заказлар ала һәм уенчыклар ясарга бирем бирә. Осталар төрле материалдан уенчыклар ясыйлар. Кабул итүче үтәлгән заказларны бирә. | |
| **Китапханә** | Укучылар китапханәгә киләләр. Алар стендлар карыйлар, китаплар сайлыйлар. Китапханәче кирәкле китапларны бирә, аларны укучылар формулярына язып куя. | |
| | **Гыйнвар** | |
| **Балалар бакчасы** | Балалар бакчасында Яңа ел бәйрәме: балалар уенчыклар ясыйлар, чыршы бизиләр, Кыш бабай белән Кар кызы киләләр, балалар Яңа ел бәйрәме һәм кыш турында шигырьләр сөйлиләр, күңелле уеннар уйнылар. | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру.Яңа ел бәйрәме турында яңа мәгълүмәтләр алу. |
| **Чәчтараш** | Чәчтарашка әниләр балалары белән киләләр. Ирләр һәм хатын- кызлар залы эшли. Осталар чәч кисәләр, кырындыралар, баш юалар, клиентларның чәчләрен тарыйлар. Алар игътибарлы һәм ягымлылар. | |
| | **Февраль** | |
| **Хәрби уеннар** | Уеннарда бик күп гаскәр төрләре катнашалар: диңгезчеләр, җәяүле гаскәр, танкистлар, очучылар. Алар командирларның әмере буенча төрле йөкләмәләр үтиләр. Хәрби уеннардан соң концерт оештыралар: җырлар җырлыйлар, бииләр. | Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү, балаларның дуслык турында мәгълүматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәнен, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгын төшендерү. |
| **Ашыгыч ярдәм** | Чакырту буенча табип килә, беренче ярдәм күрсәтә: укол ясый, тамагын карый, температурасын үлчи, рецепт язып бирә. | |

| | | |
|---|---|---|
| **Театр төзү** | Төзүчеләр театр төзиләр. Кассир билетлар сата. Тамашачылар аларны сатып алалар һәм тамашалар залына үтәләр. Аларны билет тикшерүче үткәрә. Билет тикшерүче тамашачыларга программа тәкъдим итә. Артистлар спектакльне кабатлыйлар һәм аны тамашачыларга күрсәтәләр. | |
| **Янгын сүндерүчеләр өйрәнүләрдә** | Янгын сүндерүчеләр янгын сүндерергә ашыгалар: янгын сүндерү машинасына бик тиз генә утыралар. Янган өйдән кешеләрне коткаралар, йорт хайваннарын алып чыгарга ярдәм итәләр. Янгын сүндерүчеләр баскыч, носилка кулланалар. | |
| **Март** | | |
| **Балалар бакчасы** | Тәрбияче балаларны кабул итә, иртәнге гимнастика үткәрә, балаларны ашата, алар белән уйный | |
| **Транспорт** | Йөк һәм җиңел машиналар урамда йөри, җәяүлеләр тротуардан баралар, җәяүле чыгу урыныннан юл аркылы чыгалар, бөтенесе дә юл йөрү кагыйдәләрен үтиләр. Шофер машина йөртергә хокук таныклыгы ала , машинага бензин сала, юлга чыгарга путевка ала. | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү |
| **Шәһәр буенча экскурсия** | Туристлар икенче шәһәрдән экскурсиягә килгәннәр. Экскурсовод шәһәр белән таныштыра | |
| **Кибет** | Төрле бүлекләре (табак-савыт, йорт җиһазлары, язу-сызу әйберләре һ.б.) булган яңа супермаркет ачылды. Сатып алучылар әйбер сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар (төсе, материалы, кулланылышы). | |
| **Апрель** | | |
| **Җәнлекләр шифаханәсе** | Кешеләр шифаханәгә авыру җәнлекләрне алып киләләр. Ветеринар җәнлекләрне карый, градусник куя, дару бирә, уколлар ясый | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, |
| **Аптека** | Дарулар сатучы рецеп буенча дарулар бирә. | |

| | | |
|---|---|---|
| **Уенчыклар кибете** | Сатып алучылар уенчык сайлыйлар, сатучы белән киңәшәләр, кассага акча түлиләр, чекларны сатучыга бирәләр. Сатучы сатып алучылар белән әдәпле итеп сөйләшә, аларга төрле уенчыклар тәкъдим итә, алар турында сөйли, уенчыкны бирә, сатып алучыга рәхмәт әйтә. | кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| **Почта** | Кешеләр бер-берсенә хатлар язалар, телеграмма, посылка җибәрәләр. Почта ташучы аларны адреслар буенча тапшыра. | |
| **Май** | | |
| **Шифаханә** | Терапевт кешеләрне дәвалый: тыңлый, кан басымын үлчи, тамак төбен карый, рецепт яза. Шәфкать туташы укол ясый, яраларны бәйли | Балалар бакчасының медицина кабинетына сәяхәт оештыру.Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү |
| **Хәрби уеннар** | Уеннарда төрле гаскар төрләре катнашалар: диңгезчеләр, җәяүле гаскәр, танкистлар, очучылар. Алар командир әмере буенча төрле йөкләмәләр үтиләр. Хәрби уеннардан соң концерт оештыралар: җырлар | |
| **Транспорт** | Йөк һәм җиңел машиналар урамда йөри, җәяүлеләр тротуардан баралар, җәяүле чыгу урыныннан юл аркылы чыгалар, бөтенесе дә юл йөрү кагыйдәләрен үтиләр. | |
| **Магазин** | Төрле бүлекләре (табак-савыт, йорт җиһазлары, язу-сызу әйберләре һ.б.) булган яңа супермаркет ачылды. Сатып алучылар әйбер сайлыйлар, сатучыдан алар турында сөйләвен сорыйлар ( төсе, материалы, | |

***Хезмәт***

***Аңлатма язуы***

**Культура-гигиена күнекмәләре.** Балаларда тәннең чисталыгын, киемнең, чәчнең пөхтәлеген карау; мөстәкыйль рәвештә тешләрне чистарту, юыну, кирәклектән чыгып кулларны юу, тырнакларның чисталыгын карау; йөткер-гәндә һәм төчкергәндә авызны һәм борынны кулъяулык белән каплау гадәтен формалаштыру.

Үзенең тышкы кыяфәтендәге җитешсезлекне күреп ала белергә өйрәтү һәм мөстәкыйль рәвештә тәртипкә китерү күнекмәләрен ныгыту.

Ашау культурасын: өстәл приборларыннан (чәнечке, пычак) дөрес файдалану; өстәл янында дөрес утырып, пөхтә, тавышланмыйча ашау; үтенеч белән мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү күнекмәләрен камилләштерү.

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү.** Тиз, җыйнак киенү һәм чишенү, үз шкафында тәртип саклау (өс киемен билгеле урынга төреп кую), урын-җирне пөхтә итеп җыештыру күнекмәләрен ныгыту.

Материалларны һәм әсбапларны дәрескә мөстәкыйль рәвештә һәм үз вакытында әзерли белергә, тәрбияче тарафыннан дәрес уздыру өчен әзерләнгән материалларны мөстәкыйль рәвештә урнаштырырга, аларны җыеп куярга, пумалаларны һәм буяу савытларын, палитраны юарга, өстәлләрне сөртергә өйрәтү.

**Иҗтимагый-файдалы хезмәт.** Балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хәлдән килерлек хезмәт йөкләмәләрен башкару теләге тәрбияләү. Балаларга аларның хезмәтенең мөһимлеген аңлату.

Уртак хезмәт эшчәнлегендә катнашу теләге тәрбияләү. Хезмәтнең төрле төрләрендә кирәкле сәләтләр һәм күнекмәләр формалаштыру. Мөстәкыйльлек һәм җаваплылык, башланган эшне ахырына җиткерә белү тәрбияләү. Хезмәтнең төрле төрләрен башкарганда иҗадилык һәм инициативалылыкны үстерү.

Балаларны эшнең аеруча бәрәкәтле алымнары белән таныштыру.Хезмәт эшчәнлеге культурасы, материалларга һәм инструментларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү.

Үз эшенең нәтиҗәсен бәяләргә өйрәтү(өлкән кеше ярдәмендә).Балалар арасында дустанә мөнәсәбәтләр; бергәләп уйнау, эшләү, шөгыльләнү гадәте тәрбияләү. Бер-береңә ярдәм итү теләген үстерү.Балаларда уку-өйрәнү эшчәнлеге алшартлары (элементлары) формалаштыру.
Игътибарны, куелган бурычны (нәрсә эшләргә), аны башкару ысулларын (ничек эшләргә) аңлауны үстерүне дәвам итү; түземлелек тәрбияләү; ахыргы нәтиҗәгә ирешү өчен үҗәтлек, максатка омтылучанлык күрсәтергә өйрәнү.

Балаларны төркемдә зурларга тәртип саклауда булышырга: уенчыкларны, төзелеш материалын һ.б. сөртеп куярга өйрәтүне дәвам итү.

Балалар бакчасы участогында тәртип урнаштыру (сукмакларны себерү һәм чүптән, кышкы чорда кардан чистару, комлыкта комга су сибү һ.б.) күнекмәләрен формалаштыру.

Ашханәдә дежурлык вазифаларын:табын әзерләү, ашаганнан соң өстәлне җыештыруны намуслы башкарырга өйрәтү.

**Табигатьтәге хезмәт.** Табигать почмагында хайваннарны һәм үсемлекләрне карау-тәрбияләү белән бәйле төрле йөкләмәләрне;табигать почмагында дежурлык вазифаларын (бүлмә үсемлекләренә су сибү, туфракны йомшарту һ.б.) башкару теләген хуплау.
Балаларны табигатьтә өлкәннәргә ярдәм итүгә һәм хәлдән килерлек эшкә: көзен — яшелчә бакчасында уңышны җыеп алуга, орлык җыюга, чәчәкле үсемлекләрне грунттан табигать почмагына күчереп утыртуга; кышын — агач кәүсәләренә һәм куаклыкларга таба кар көрәүгә, кошлар һәм җәнлекләр (табигать почмагында яшәүчеләр) өчен үлән үстерүгә, тамыразыклар утыртуга, кардан сыннар һәм корылмалар төзүгә; язда туфрак йомшартуга, түтәлләргә һәм клумбаларга су сибүгә җәлеп итү.

**Өлкәннәр хезмәтенә ихтирам.** Балаларның өлкәннәр хезмәте, хезмәт-нең нәтиҗәләре, иҗтимагый әһәмияте турындагы күзаллауларын киңәйтү. Кеше куллары белән эшләнгән әйберләргә карата сакчыл мөнәсәбәт форма-лаштыру. Балаларда кешеләргә карата хезмәтләре өчен рәхмәтле булу хисе тәрбияләү.

***Комплекслы-тематик план***

| **Тема** | **Интеграция** |
|---|---|
| ***Сентябрь*** | |
| 1.Табын әзерләү, ашау әйберләрен дөрес кую- кашык һәм пычакны – тәлинкәнең уң ягына,чәнечкене – сул ягына кую, ашаганнан соң савыт-сабаны өсәлдән җыеп алу күнекмәләрен ныгыту.<br>2.Иптәшләренә шөгыль өчен материал әзерләргә ярдәм итүкүнекмәләрен ныгыту.<br>3.Балаларны үз бүлмәләрен һәм мәйданчыкны һәрвакыт тәртиптә тотарга: уенчыкларны, төзү материалларын үз урыннарына куярга, тәрбияче белән берлектә китап һәм уенчыкларны рәтләргә, чишенү шкафларын тәртиптә тотарга өйрәтү | *Уку:* һөнәрләр турында хикәяләр уку, шофёр һөнәре буенча рәсемнәр карау<br>*Аралашу:* балалар бакчасында азык – төлек алып килүче машиналарны күзәтү, күргәннәр буенча әңгәмә оештыру. |
| ***Октябрь*** | |
| 1.Математика өчен материалны таратырга: линейка, конвертлар, таратма материалларны; шөгыльдән соң бар материалны җыяргаөйрәтү.<br>2.Уенчыклар шкафын җыештыру, өстәл уеннарының тышларын рәтләү, бизәү әйберләре, бәйрәмнәргә костюмнар әзерләүдә катнашу.<br>3.Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Һәр көн саен юыну һәм тешләрен чистарту,ашау алдыннан һәм пычранган саенкулларын юу күнекмәләре бирү.Билгеле бер эзлеклелектә киенә һәм чишенә, киемне дөрес һәм пөхтә итеп шкафка, аяк киемен үз урынына куя, дымланган киемнәрне вакытында киптерә, аяк киемнәренкарап-чистартып (юу, сөртү, ялтырату) торырга гадәтләндерү.Үзендәге җыйнаксызлыкны күреп, тәртипкә китерергә, иптәшенә аның өс-баш һәм аяк киемендәге төгәлсезлекне әдәпле итеп кенә искәртергә, аларны бетерүдә булышлык итәргә өйрәтү. Үзара ярдәмләшү тойгысы тәрбияләү.<br>4. Дежурлык бурычларын мөстәкыйль һәм намус белән башкарырга өйрәтү. | *Сәламәтлек:* үз – үзеңне тәртиптә тотарга кызыксындыру, шәхси гигиена таләпләрен үтәргә өйрәтү.<br>*Куркынычсызлык:* хезмәт кирәк– яракларыннан дөрес куллану һәм аларны дөрес урнаштыру күнекмәләрен фолмалаштиыру. |
| ***Ноябрь*** | |

| | |
|---|---|
| 1.Табигать почмагындата дежур тору: үсемлекләргә су сибү, кипкән яфракларын алу, һава торышыкалендарен алып барырга булышу.<br>2.Ябыштыру шөгыленнән соң өстәлдән кәгазь кисәкләрен җыеп алырга күнектерү.<br>3.Балаларны үз бүлмәләрен һәм мәйданчыкны һәрвакыт тәртиптә тотарга: уенчыкларны, төзү материалларын юып - сөртеп торырга, тәрбияче белән берлектә китап һәм уенчыкларны рәтләргә өйрәтү. Балалар бакчасы мәйданчыгында мөстәкыйль рәвештә җыештыру эшләре үткәрергә: юлларны себереп, чүп-чардан, кардан чистартырга.<br>4. Йокыдан торгач, урын-җирне мөстәкыйль җыештырырга ойрәтү. | *Уку:* пешекче һөнәре турында хикәяләр уку, рәсемнәр карау.<br>*Аралашу:* балалар бакчасы ашханәсенә экскурсия, пешекче эшен күзәткәннән соң, хикәя төзергә өйрәтү.<br>*Социальләштерү:* кушылган эшкә карата җаваплылык формалаштыру. |
| ***Декабрь*** | |
| 1.Табынны тиз һәм пөхтә җәя һәм җыя белү күнекмәләрен ныгыту.<br>2.Шкафтан шөгыльгә кирәкле материалны алырга, махсус өстәлгә урнаштырыга, иптәшләренә аларны шөгыльгә әзерләргә, шөгыльдән соң җыеп куярга ярдәм итү, нәфасәти шөгыльләрдән соң өстәлләрне сөртергә.<br>3.Балаларны үз бүлмәләрен һәм мәйданчыкны һәрвакыт тәртиптә тотарга: тәрбияче белән берлектә китап һәм уенчыкларны рәтләргә, чишенү шкафларын тәртиптә тотарга, китапларны рәтләргә өйрәтү.<br>4.Уен мәйданчыгын җыештыру: себерү, чүп җыю, веранда җыештыру, уен мәйданчыгын кардан чистарту, карны өешер өчен һәм корылмалар төзер өчен өемнәргә җыярга, корылмаларны кардан чистартырга.. Яшелчә һәм чәчәк түтәлләренә кар ташырга.Куакларны, агачларның аскы өлешләрен кар белән капларга. | *Социальләштерү:* балаларны шәхси һәм тәркемләп кушылган эшләрне үтәргә тарту, бер–берсе арасында тәрбияче ярдәме белән эшне бүлергә өйрәтү.<br>*Уку:* зурлар хезмәтенең кирәклеге турында хикәяләр уку, зурлар хезмәтен хөрмәт итү турында үрнәк китерү.<br>*Аралашу:* хезмәтнең җәмгыять, гаилә һәм балалар бакчасы өчен кирәклеге турында сөйләшү. |
| ***Январь*** | |
| 1.Шөгыльләргә эш урынының әзерлеген күзәтергә, балаларның эш урынын шөгыльгә җитмәгән материал белән тулыландырырга.Җыр шөгыльләренә әйбер әзерләүдә катнашырга.<br>2.Уен почмакларын тәртипкә китерү; төзү материалларын, өстәл уеннарын, хезмәт өчен материалны һәм эш коралларын урынына алып куярга.<br>3.Шөгыльгә киткәндә, урамга чыкканда бар да тәртиптә калуын тикшерү: шкафлардагы, урындыклардагы киемнәрнең төрелү тәртибен, балалар җыештырганнан соң караватлар тәртибен карау. | *Социальләштерү:* башланган эшне азагына кадәр эшләүне тәрбияләү, аны яхшы эшләүне булдыру.<br>*Аралашу:* врач хезмәте буенча сөйләшү, рәсемнәр карау, теманы тикшерү теләге уяту. |

| | |
|---|---|
| 4.Кардан корылмалар, кечкенәләр өчен тау ясауда катнашу. Юлларга ком сибү. | |
| ***Февраль*** | |
| 1.Ябыштыру шөгыле өчен кәгазь хәзерлек әзерләргә, физкультура шөгыле өчен җиһазлар әзерләүдә һәм урнаштыруда катнашу, шөгыльдән соң эш урыннарынтәртипкә китерергә.<br>2.Тартмага ашар өчен яшеллеккә суган утыртырга.<br>3. Кыш турында йомгаклау әңгәмәсе өчен һава торышы календаре әзерләү.<br>4.Төзәтелергә тиешле уенчыкларны, китапларны, тартмаларны сайларга.<br>5. Уенчыкларны һәм төзү материалларын юарга, сөртергә.<br>6. Билгеле бер тәртиптә урындакларны тезәргә. | *Куркынычсызлык:* карны күрәгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне формалаштыру.<br>*Танып белү:* табигать почмагындагы гөлләрнең һәм усемлекләрнең исемнәрен белү. |
| ***Март*** | |
| 1.Табынны тиз һәм пөхтә җәя һәм җыя белү күнекмәләрен ныгыту.<br>2.Шкафтан шөгыльгә кирәкле материалны алырга, махсус өстәлгә урнаштырыга, иптәшләренә аларны шөгыльгә әзерләргә, шөгыльдән соң җыеп куярга ярдәм итү, нәфасәти шөгыльләрдән соң өстәлләрне сөртергәкүнектерү.<br>3.Үсемлекләрне коендырырга, ашар өчен яшеллеккә суган утыртырга.<br>4.Уен почмакларын тәртипкә китерү; төзү материалларын, өстәл уеннарын, хезмәт өчен материалны һәм эш коралларын урынына алып куярга.<br>5. Шөгыльгә киткәндә , урамга чыкканда бар да тәртиптә калуын тикшерү:шкафлардагы, урындыклардагы киемнәрнең төрелү тәртибен, балалар җыештырганнан соң караватлар тәртибен.<br>6. Уен мәйданчыгын, веранданы, чистартырга.Тәрбиячегә кар таратырга ярдәм итү. | *Аралашу:* йорт хайваннарын караучы хезмәте турында сөйләшү. |
| ***Апрель*** | |
| 1.Шөгыльләргә эш урынының әзерлеген күзәтергә, балаларның эш урынын шөгыльгә җитмәгән материал белән тулыландырырга.<br>2.Җыр шөгыльләренә әйбер әзерләүдә катнашырга.<br>3.Кошларга яшел ашамлык өчен ашлык бөртекләре чәчәргә өйрәтү. Күзәтү өчен кузаклы үсемлекләр утырту.<br>4.Уенчыклар шкафын җыештыру, өстәл уеннарының тышларын рәтләү, бизәү әйберләре, бәйрәмнәргә костюмнар әзерләүдә катнашу. | *Уку:* С. Михалков «Почта», 1 өзеген ятлау.<br>*Аралашу:* балаларга почтальон (хат ташучы) хезмәте турында сөйләү. |

| *Май* | |
|---|---|
| 1Ябыштыру шөгыле өчен кәгазь хәзерлек әзерләргә, физкультура шөгыле өчен җиһазлар әзерләүдә һәм урнаштыруда катнашу, шөгыльдән соң эш урыннарынтәртипкә китерергә<br>2.Төркем бүлмәсендә үстерелгән чәчәкләрне чәчәк түтәленә күчереп утыртуда катнашу.<br>3.Тәрбияче кушуы буенча алып чыгу өчен материалны һәм уенчыкларны сайлап алып урамга алып чыгарга. Керер алдыннан уенчыкларны җыярга һәм аларны тәртипкә китерергә.Уен мәйданчыгын, веранданы җыештыру. | *Аралашу:* үсемлекләрнең үсешен күзәтү, күргәннәр буенча сөйләшү.<br>*Социальләштерү:* уеннарда рольләрне дөрес башкаруны ныгыту. |

“Социаль-шәхси үсеш” белем өлкәсе җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.
Тематик план интеграция принциплары һәм төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләрен формалаштыру федераль дәүләт белем бирү стандартына нигезләнеп төзелгән.

***Куркынычсызлык***
***Аңлатма язуы***

«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәмбелем бирү бурычларынбилгели.

**Табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү**. Экологик культура һәм табигатьтә куркынычсызлык кагыйдәләре нигезләрен формалаштыру.

Табигатьтә бар нәрсәнең үзара бәйләнештә булуы, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясына зыян китермәү өчен кешенең бу үзара бәйләнешне бозарга тиеш түгеллеге турында төшенчәләр формалаштыру.

Терек булмаган табигать күренешләре (яшенле яңгыр, күк күкрәү, яшен, салават күпере), яшенле яңгыр вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Балаларны бәрелгәндә һәм бөҗәкләр тешләгәндә беренче ярдәм күрсәтү кагыйдәләре белән таныштыру.

Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү. Балаларның юл элементлары (машина юлы, җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу урыны, тротуар), транс-порт хәрәкәте, светофор эше турындагы белемнәрен ачыклау. Балалар бакчасына якын урнашкан урамнар һәм балалар яши торган урамнарның исемнәре белән таныштыру.

Юл хәрәкәте кагыйдәләре, җәяүлеләр һәм велосипедчылар хәрәкәте кагыйдәләре белән таныштыру.

«Балалар», «Трамвай тукталышы», «Автобус тукталышы», «Җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу урыны», «Беренче медицина ярдәме күрсәтү пункты», «Туклану пункты», «Машина кую урыны», «Керү тыела», «Юл эшләре», «Велосипед юлы» дигән юл билгеләре белән таныштыруны дәвам итү.

Үз тормыш эшчәнлегеңнең куркынычсызлыгы. Кешенең тереклек эшчәнлеге иминлеге нигезләрен ныгыту.

Елның төрле фасылларында уен вакытында (сулыкларда коену, велосипедта йөрү, чанада, тимераякта, чаңгыда шуу һ.б.) куркынычсызлык кагый-дәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Көнкүрештәге хәвеф чыганаклары (электр приборлары, газ плитәсе, үтүк һ.б.) турындагы белемнәрне киңәйтү. Көнкүреш предметларыннан хәвефсез файдалану күнекмәләрен ныгыту.

Балаларның янгын сүндерүчеләр, янгыннарның сәбәпләре, янгын вакытында үз-үзеңне тотуның элементар кагыйдәләре турындагы белемнәрен ачыклау. Коткару хезмәте — МЧС эше белән таныштыру. Бик кирәк булган очракта өлкәннәрнең «01», «02», «03» телефоннары буенча шалтыратулары турындагы белемнәрне ныгыту.

Ярдәм сорап өлкәннәргә мөрәҗәгать итә белү күнекмәләре формалаштыру.

Баланы үз исемен, фамилиясен, яшен, өй адресын, телефонын атарга өйрәтү.

***Комплекслы - тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар | Интеграция |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | I | Тема: «Җәй безгә сәламәтлек өстәде». | Мөстәкыйль рәвештә үз сәламәтлекләре турында кайгыртырга өйрәтү, җәйге су, һаваның кеше сәламәтлегенә йогынтысы,ничек сәламәт булырга булышулары турында аңлату. | *Танып-белү:* д/у “Нинди агач яфрагы”<br>*Аралашу:* Әңгәмә: “Без җәй көне ничек ял иттек” |
| | II | Тема: «Велосипедта йөрү кагыйдәләр» | Уң яктан кагыйдәләрне төгәл үтәп велосипедта йөрергә өйрәтүне дәвам итү,төгәл һәм игътибарлы булырга өйрәтү. | *Аралашу*: Әңгәмә “Минем дустым-велосипед”<br>Д/уен”Светофор”,<br>“Хәрәкәт кагыйдәләре”<br>С/р уен. “Транспорт” |
| | III | Тема: «Төркем бүлмәсендә тәртип булырга тиеш» | Балаларны төркем бүлмәсендә чисталык һәм тәртип тотарга өйрәтү, ничек уенчыкларны дөрес итеп урнаштырырга аңлату. | *Аралашу*: Әңгәмә “Ниөчен төркем бүлмәсендә тәртип булырга тиеш”<br>Д/уен”Нәрсә кайда тора?” |
| | IV | Тема: «Синең кәрзиндә ниләр бар?» | Ашарга яраклы һәм агулы гөмбәләр, җимешләр турындагы күзаллаулар бирү, аларны аерым билгеләре буенча аерырга өйрәтү. | *Иҗади сәнгать*: ябыштыру «Гөмбәләр».<br>“Табышмак әйтәм,тап”<br>Д/уен”Ашарга яраклы, яраксыз гөмбәләр”рәсемнәр карау |
| Октябрь | I | Тема: «Игътибар, грипп» | Үз сәламәтлекләре турында кайгыртырга өйрәтү: авыруның билгеләре, авыруны булдырмау чаралары белән таныштыру, алар турында сөйләргә өйрәтү | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: Әңгәмә “Грипп, “Безнең организм ничек эшли”<br>Уен-бирем “Дөрес-дөрес түгел”<br>С/р уен. “Шифаханә”<br>*Иҗади сәнгать*: рәсем “Микроблар” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | II | Тема: «Җәмәгать транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре» Уен «Без барабыз, барабыз….» | “Куркынычсызлык утравы” билгесе һәм әһәмияте белән таныштыру. Җәмәгать транспортында үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү. | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: “Без автобуста барабыз” с/р уен.”Транспорт” *Иҗади сәнгать*: рәсем “Автобус” |
| | III | Тема: «Ут белән сак бул». | Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышуныдәвам итү, янгын сүндерүче хезмәтенә кызыксыну уяту. | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: Әңгәмә”Куркыныч-куркыныч түгел” *Уку*: С. Маршак «Песи өе» Уен-хәл “Синең квартирада янгын, “01” гә шалтырат” |
| | IV | Тема: «Көзге урманда үзеңне тоту кагыйдәләр” | Көзге урманда үзеңне тоту, табигатькә сак карау, “кечкенә туганнарыбызны” кыерсытмау кагыйдәләре белән танышуны дәвам итү. | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*: Әңгәмә “ Көзге урманга сәяхәт” Уен-бирем “Гөмбәләрне кәрзингә Җый *Иҗади сәнгать*: рәсем «Гөмбәләр». |
| ноябрь | I | Тема: «Кем безнең сәламәтлек турында кайгырта». *Медицина кабинетына экскурсия* | Табиб хезмәте белән танышуны дәвам итү, игътибарлылык, сизгерлек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү. | *Тәҗрибә эшчәнлеге:* Тән температурасын, буйны үлчәү С/р уен. “Тикшерү үзәге” |
| | II | Тема: «Юлда куркынычсызлык». *Дидактик уен* «Юл йөрү кагыйдәләрен бел һәм үтә” | Юлда көтүче куркынычлар турында, юлда йөрү кагыйдәләре турында белемнәрне, светофорның төсләрен, юл билгеләрен ныгыту, игътибарлылык тәрбияләү. | Урамга экскурсияМӘУ.С.Михалков “Скверная история”, Н.Носова “Милиционер” Әңгәмә “Без-җәяүлеләр” |
| | III | Тема: «Өйдә куркыныч әйберләр». | Тормыштагы куркыныч әйберләр,аларны куллану, куллану кагыйдәләрен, турындагы күзаллауларны ныгыту. | Куркыныч әйберләр, шартлар төшерелгән рәсемнәркарау. Әңгәмә:”Тәрәзәдән чыкма” Д/уен “Дөресме бу?” |
| | IV | Тема: «Җылырак киен». | Үз сәламәтлегең турында кайгыртуны дәвам итү, һава торышына карап киенергә, башлык кияргә, шарф бәйләргә күнектерү. | Аралашу: “Ни өчен җылы киенергә кирәк”. Уен-бирем “Курчакны тышта йөрергә киендер” Уен-хәл “Незнайка тышта йөрергә чыга” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| декабрь | I | Тема: «Сәламәтлегеңне үзең кайгырт» | «Вирус, микроб» төшенчәләре кертү. Чирләрдән котылу чаралары белән таныштыру, авыганда терелә чаралары турында сөйләшү. Чыныктыру һәм витаминнарның файдасын аңлату | *Аралашу:*әңгәмә "Ни өчен спорт белән шөгыльләнергә" *Уку:*К. Чуковский «Айболит» (уку һәм өзеген ятлау)<br>Тренинг «Үзеңә массаж»<br>Д/у "Нәрсә-ни өченСЯР (ЗОЖ) турында рәсемнәр карау<br>Д/уен«Юыну кирәк-яраклары» |
| | II | Тема: «Игътибар, урам!» | Куркыныч хәлләрдән саклау,саклык, ихтибарлылык сыйфатларын үстерү, таныш түгел кешеләр белән үзеңне тоту кагыйдәләренөйрәнү. | *МӘТ Уку:* "Казлар-аккошлар"<br>Д/уен "Юл билгеләре"<br>с/р уен "Трамвайда сәяхәт"<br>*Иҗади сәнгать: рәсем*"Зебра" |
| | III | Тема: «Чыршы утлары» | Балаларны чыршы уенчыклары белән эш итәргә, зурлар беләнчыршы бизәргә, төгәл, сак булырга, зурлардан башка чыршы утларын кабызмаска өйрәтү | Аралашу: Әңгәмә "чыршыны ничек бизәргә<br>"Гирляндалар матур, ләкин куркыныч"<br>Уен-бирем "Чыршыны бизә"<br>Д/уен "Ватыла-ватылмый"<br>Чыршы уенчыклары ясау |
| | IV | Тема: «Хайваннар белән ничек үзеңне тотарга». | Төрле хайваннар белән очрашканда үзеңне тоту кагыйдәләре турында белемнәр бирү, балаларны хайваннарныңүзләрен тотышын, хәлен аңларга, алар белән аралашырга өйрәтү. Балаларны хуҗасызхайваннар белән очрашкандамөмкин булган куркыныч хәлләр турында искәртү | Аралашу: Әңгәмә "Өйсез песи"<br>МЭТ: Д.Гарифуллин<br>"Песи, песи, пескәем"<br>С.Закир "Песинең зары"<br>"Кыргый хайваннар" рәсемнәр карау.<br>*Иҗади сәнгать: рәсем*"Песи"<br>Уен "Зоопарк" |
| январь | I | Тема"Витаминнар сәламәтлекне ныгыта" | Витаминнар төшенчәсе белән таныштыру, файдалы азыклар, кеше организмы өчен витаминнарның кирәклеге турында белемнәрне ныгыту, балаларда ашау культурасы, чама хисе тәрбияләү. | *Иҗади сәнгать:*рәсем «Витаминнар"<br>Д/ уен "Тәме буенча тап"<br>*Тикшерү-тәҗрибә эше*: үз буеңны үлчәү.<br>Яшелчә, җиләк-җимешләр карау. |
| | II | Тема: «01,02,03 һәрвакыт сакта" | Коткару хезмәтләре белән танышу, әхлакъ сыйфатлары тәрбияләү, кешеләргә ярдәм итү теләге уяту. | *Уку:* янгын сүндерүчеләр, полиция хезмәткәрләре, табиблар шигырьләр уку<br>*Социальләштерү:*с/р.уен"Коткару хезмәткәрләре"<br>*Иҗади сәнгать:*рәсем «Янгын сүндерү машинасы" Д\уен "Дөресен тап" |
| | III | Тема: «Хуҗалык | Хуҗалык җиһазларының кулланылышы, аларны | Рәсемнәр карау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | җиһазлары- кешенең ярдәмчеләр» | куллану турында белемнәрне ныгыту, игътибарлылык, сакчыллык, төгәллек сыйфатлары тәрбияләү. | *Аралашу*: Әңгәмә “Йорт булышчылары ничек эшли”<br>Д/уен “Электр приборын бел” |
| | IV | Тема: «Сак бул, бозлавык!» | Кышкы юлның үзенчәлекләре белән таныштыру, куркынычсызлык кагыйдәләренүтәүне булдыру. Бозлы юлда сак йөрүне кисәтү, егылганкешегә беренче ярдәм күрсәтергә тәкъдим итү. | *Аралашу*: Әңгәмә “Сабул, бозлавык”<br>С/р уен “Травпункт”<br>Уен-бирем “Торырга булыш”<br>Рәсемнәр карау<br>*Аралашу:* әңгәмә” Кышкы юлда һәм сулыкларда үзеңне тоту кагыйдәләре”, |
| февраль | I | Тема: “ Теш щеткасы белән дуслаш». | Шәхси гигиена кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү,теш щеткасы, теш пастасы, аларның кулланылышы турында күзаллаулар бирү, теш чистарту юллары белән таныштыру. | *Иҗади сәнгать*: рәсем «Теш һәм теш щеткасы». Уку: Г.Юнысова “Тешләр”<br>Д/уен “Тешләр өчен нәрсә файдалы”<br>С/р уен “Теш дәвалау оешмасы” |
| | II | Тема: «Юл билгеләре-ярдәмчеләр»<br>*Сюжетлы-рольле уен* «Шофер» | Балаларның юл билгеләре турындагы белемнәрен өйрәтүне дәвам итү, тыючы һәм рөхсәт итүче билгеләр белән таныштыру, игътибарлылык тәрбияләү | *Аралашу:*әңгәмә«Куркынычсызлык әлифбасы»<br>Д/уен “Билгене әйт”, “Билгене җый”<br>Уен-бирем “Төгәлләнмәгән рәсем-сызым”<br>Уку: Т.Александрова «Светофорчик», Ш.Галиев “Светофорның өч сүзе” |
| | III | Тема: «Өйдә берүзем». | Өйдә берүзең калган вакытта үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәнү, ишекне ятларга ачмау, электр җиһазларын кушмау, сакчыллык сыйфатлары тәрбияләү. | Аралашу: «Өйдә берүзем.», “Берүзем урамда йөрим”<br>Уен-хәл “Кем ишек кага”.<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга” |
| | IV | Тема: «Тылсымлы су» | Суга – табигать ресурсына сак караш кирәклеген аңларга өйрәтү, суның үзлекләре белән танышу | Су белән тәҗрибәләр<br>Аралашу: Әңгәмә “Суның үзлекләре”<br>Табигатьтә суның өзлексез әйләнеше<br>Д/уен “Су тегермәне”<br>Уен-бирем “Су тамчысы нәрсәгә охшаган” |
| март | I | Тема: «Гәүдә-матур арка». | Үз сәламәтлегең турында кайгыртырга өйрәнү, физик күнегүләр ясарга теләк уяту, үзенең нәтиҗәсеннән куаныч табу. | Балалар белән гәүдәне ныгыту өчен күнегүләр ясау<br>Скакалка һәм кыршау белән уеннар |
| | II | Тема: «Җәмәгать транспорты | Балаларны җәмәгать транспорты тукталышларында үзеңне тоту тәртибенә өйрәтү,игътибарлылык, | *Аралашу:*әңгәмә «Җәмәгать транспорты тукталышларында үзеңне ничек тотарга» |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | тукталышларында тәртип». | сакчыллык тәрбияләү | Д/ уен “Юл билгеләре”<br>Уен-хәл”Транспортны ничек урап үтәргә” |
| | III | Тема: “Куркыныч тәкъдим” | Ят кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә, әйләнә-тирәгә игътибарлы булырга өйрәтү, сакчыллык сыйфатлары тәрбияләү. | *Аралашу:*әңгәмә«Ят кешеләр белән аралашу»<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга” |
| | IV | Тема: «Сак бул, боз китә» | Балаларга боз киткәндә үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлату, елгаларга якын бармаска,куркыныч урыннардан ерак йөрергә, сак булырга өйрәтү. | *Аралашу:*әңгәмә «Сак бул,боз китә»<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга”<br>Рәсемнәр карау |
| апрель | I | Тема: «Спорт –ул сәламәтлек» | Спорт төрләре, Олимпиада турында белемнәрне ныгыту, таныш спорт төрләрен пантомимо белән күрсәтергә өйрәтү, спортка кызыксыну, спорт белән шөгыльләнергә теләк уяту. | Уен-бирем “Тәмамланмаган рәсем-схема”<br>*Аралашу:* әңгәмә «Спорт», “Олимпиада”.<br>*Иҗади сәнгать:* төзү«Минем урам».<br>*Аралашу:* әңгәмә «Юлны ничек үтәргә”, “уң кул кагыйдәсе”<br>*Уку:* Р.Бәшәр “Кызыл ут”<br>С\Р уен “Җәяүле”<br>Җәяүлеләр өчен юл билгеләрен карау |
| | II | Тема: «Җәяүле культурасы» | Балаларны юлдан чыгу, юлның уң ягыннан йөрү, юлны светофор яшел янганда гына үтәргә кирәк кебек кагыйдәләр белән таныштыруны дәвам итү, игътибарлы һәм сак булырга өйрәтү. | |
| | III | Тема: «Дарулар һәм витаминнар” | Балаларга аптечкадан сораусыз дару һәм витаминнар алырга ярамаганны аңлату, бары нәрсә алырга ярый, нәрсә юк икәнен сорап кына алырга. | *Аралашу:* әңгәмә “Минем аптечка”,<br>Уен-хәл “Нәрсә аптечкада булырга тиеш”<br>Д/уен “Күңелсез хәлләрдән ничек качарга” |
| | IV | Тема: «Яз көне урманда тавышланырга ярамый» | Балаларның урманда үзләрен тыныч тотарга, үзенә, әйләнә- тирәгә игътибарлы булырга, үзебезнең кече туганнарыбызны рәнҗетмәскә өйрәтү. | *Аралашу:* әңгәмә “Урманда үзеңне тоту”<br>Уку: яз көне кошлар турында шигырьләр<br>*Иҗади сәнгать: рәсем* “Яз көне урман”<br>Әвәләү “Кош оясы” |
| май | I | Тема: “Безнең куллар” | Кулларның мөһимлеге, кул белән баш миенең бер-берсе белән бәйләнеше, кулны үстергәндә без телне дә үстерелүе турында төшенчәләр бирү, кул моторикасын үстерүнең кирәклеген төшендерү. | *Физик культура:* х/у “Водяной”<br>Уен-бирем “Шнурны бәйлә”<br>*Аралашу:әңгәмә* “Кеше куллары”<br>Уку: кул турында шигырь.<br>Психогимнастика “Без куллар белән изгелек эшлибез” |
| | II | Тема: «Юлда җәяүле».<br>*Дидактик уен* «Светофорны җый» | Алган белемнәрне кулланып юлда йөрү күнекмәләрен камилләштерү, светофор турында белемнәрен ныгыту. | *Физик культура:* хәрәкәтле уеннар “Төсле автомобильләр”,<br>“Чыпчыклар һәм автомобиль”<br>*Аралашу:әңгәмә* “Без урамда уйныйбыз”, “Юл билгеләре” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | С/р уен. “Автобус”;Д/уен “Юл билгеләре” |
| | III | Тема: «Пычрак чебен» | Чебеннәрнең куркынычлыгы турында, шәхси гигиена кагыйдәләрен (ашар алдыннан кулларны юу) үтәргә кирәклеге турында балаларның күзаллауларын ныгыту | Уку: К.Чуковский “Федорино горе”, “Муха-грязнуха” әкияте<br>Уен “Әйе-юк”<br>*Иҗади сәнгать: рәсем* “Чебен” |
| | IV | Тема: «Сак бул, яшен». | Балаларны табигатьтә яшен вакытында үз-үзләрен тоту кагыйдәләре (йөгермәскә, агач төбенә качмаска, суга кермәскә, тимергә тотынмаска) белән таныштыру. | Уен: “Табышмак әйтәм, тап”<br>Уку: А.Барто “Яшен”, Г.Рәхим “Яшенле яңгыр” |

## 2.3.2. «ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ» белем бирү өлкәсе

***ЭЛЕМЕНТАР МАТЕМАТИК ТӨШЕНЧӘЛӘР ФОРМАЛАШТЫРУ***

***Аңлатма язуы***

«Танып белү үсеше баланың мәнфәгатьләре, кызыксынучанлыгы һәм танып белү омтылышы үсешен; танып белү гамәлләре, аңы формалашуын; хыялы һәм иҗади активлыгы үсешен; үзе, башка кешеләр, әйләнә-тирәдә-ге объектлар, әйләнә-тирәдәге объектларның үзлекләре һәм үзара бәй-ләнешләре (форма, төс, үлчәм, материал, яңгыраш, ритм, темп, микъдар, сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт, хәрәкәт һәм тыныч халәт, сәбәпләр һәм нәтиҗәләр һ.б.), туган җир һәм Туган ил турындагы беренчел күзаллаулары, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, Ватаныбызның традицияләре һәм бәйрәмнәре, кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты була-рак Җир планетасы, аның табигатенең үзенчәлекләре, дөньядагы илләрнең һәм халыкларның күптөрлелеге турындагы күзаллаулары формалашуын күз алдында тота»

**Элементар математик күзаллаулар формалаштыру.** Элементар математик күзаллаулар, әйләнә-тирә объектларының төп сыйфатлары һәм бәйләнешләре: форма, төс, үлчәм, микъдар, сан, өлеш һәм бөтенлек, тирәлек һәм вакыт турындагы беренчел күзаллаулар формалаштыру.

**Микъдар һәм исәп.** Төрле сыйфатлы элементлардан (төрле төстәге, зурлыктагы, формадагы, кулланылыштагы предметлардан; тавышлар-дан хәрәкәтләрдән) күплекләр (предмет төркемнәре) төзергә өйрәтү; күплекләрне өлешләргә таркату һәм шул өлешләрне яңадан кушу; тулай күплек һәм аның һәр өлеше арасындагы бәйләнешне ачыклау, күплекнең өлештән зуррак, ә өлешнең тулай күплектән азрак (кечерәк) булуын аңлау; санау-исәпләү һәм бер элементны (предметны) икенчесе белән тиңләштерү нигезендә күплекнең төрле өлешләрен чагыштыру; күплекнең зур (кечкенә) өлешен яки аларның тигезлеген ачыклау.

10 га кадәр санарга өйрәнү; әзлекле рәвештә 5 тән 10 га кадәр чикләрдә һәр санның ясалуы белән таныштыру (әсбап нигезендә). Балаларны санның предметларның зурлыгына, предметлар арасында-гы арага, формага, предметларның урнашуына, шулай ук санау-исәпләүнең юнәлешенә (уңнан сулга, сулдан уңга таба, теләсә кайсы предметтан башлап) бәйле булмавын аңларга өйрәтү.

Конкрет материал мисалында 5 чикләрендә санның берәмлекләрдән тор-ган микъдар составы белән таныштыру: 5 — бер, тагын бер, тагын бер, тагын бер һәм тагын бер.

**Зурлык.** Төрле озынлыктагы (биеклектәге, киңлектәге) яки калынлыкта-гы 5–10 предмет арасындагы зурлык чагыштырмаларын ачыкларга өйрәтү: зурлыклары буенча үсә (кими) бару тәртибендә урнаштырып, предметлар-ны системалаштыру; сөйләмдә предметларның урнашу тәртибен һәм алар арасындагы зурлык чагыштырмасын чагылдыру: «Алсу тасма — иң киңе, шәмәхә тасма — бераз таррак, кызыл тасма тагын да таррак, ләкин ул сары тасмадан киңрәк, ә яшел тасма сарысыннан һәм барлык башка тасмалардан да таррак» һ.б.

Зурлык (озынлык, киңлек, биеклек) буенча ике предметны өченчесе (шартлы үлчәү берәмлеге), чагыштырылучы предметларның берсенә тиң предмет ярдәмендә чагыштыру.

Күз үлчәмен, үрнәк итеп алынган предметтан озынрак (кыскарак), биегрәк (тәбәнәгрәк), киңрәк (таррак) һәм аңа тиң предметларны эзләп таба белү сәләтен үстерү.

Предметны (кәгазь бите, тасма, түгәрәк, квадрат һ.б.) берничә (ике, дүрт) тигез өлешкә бүлеп булуны аңлауны формалаштыру.

Бүлгәннән соң барлыкка килгән өлешләрне атарга, бербөтенне һәм өлешләрне чагыштырырга, бербөтен предметның аның барлык өлешләреннән зуррак, ә өлешнең бербөтеннән кечерәк булуын аңларга өйрәтү.

**Форма.** Түгәрәк һәм турыпочмаклык белән чагыштыру нигезендә бала-ларны овал белән таныштыру.

Дүртпочмаклык турында күзаллау булдыру: квадрат һәм турыпочмаклыкның дүртпочмаклык төрләре булуын аңлауга ирешү.

Балаларда геометрик күрү үткенлеге: предметларны формалары буенча анализлау һәм чагыштыру, якын-тирәдәге бертөрле һәм төрле формадагы предметларны: турыпочмаклык рәвешендәге китапларны, картинаны, оде-ялны, өстәл капкачларын, овал рәвешендәге поднос һәм зур тәлинкәне, түгәрәк әйберләрдән тәлинкәләрне һ.б. таба белүне үстерү.

**Тирәлектә ориентлашу.** Тирәлектә ориентлашуны камилләштерү; тирәлектәге чагыштырмалар мәгънәсен аңлау (өстә — аста; алда (алдында) — артта (артында), сулда — уңда, арасында, янәшәсендә, янында); сигналлар буенча үзгәртүләр белән, шулай ук билгеләр — хәрәкәт юнәлешләре күрсәткечләре (алга, артка, сулга, уңга һ.б.) буенча билгеләнгән юнәлештә хәрәкәт итү; тирәлектәге кешеләр һәм предметлар арасында үзеңнең урыныңны ачыклау: «Мин Алсу һәм Гөлназ арасында, Мансур артында, Гүзәлдән арттарак (аның артында), Нәҗия алдында, Аяз янында басып торам», сөй-ләмдә предметларның үзара торышын күрсәтү: «Курчактан уңда куян утыра, ә курчактан сулда ат басып тора, артта — аю баласы, ә алда — машина».
10 га кадәрге чикләрдә конкрет күплекләрне чагыштыру нигезендә янәшә торучы саннарны чагыштыру; кечерәк күплеккә бер предмет өстәп яки зуррак күплектән бер предметны алып, тигезсезлектән тигезлек (тигезлектән ти-гезсезлек) булдыру («8 дән 7 кечерәк, әгәр 7 гә бер предмет өстәсәк, 8, тигез була»; «7 дән 8 зуррак, әгәр 8 предметтан бер предметны алсак, 7 шәр, тигез була»).Янәшә торган саннарның чагыштырмаларын аңлау сәләте формалашты-ру (5<6 дан 1 гә, 6>5 тән 1 гә). Зур күплектән предметларны үрнәкләре һәм билгеләнгән сан буенча са-нап аерып алу (10 чикләрендә).
Туры һәм кире тәртиптә санау тәртибен камилләштерү (10 чикләрендә). Предметларны капшап санау, авазларны, хәрәкәтләрне үрнәкләре һәм билгеләнгән сан буенча санау һәм кабатлау (10 чикләрендә). 0 дән 9 га кадәр саннар белән таныштыру.
10 чикләрендә тәртип буенча санау белән таныштыру, «Ничә?», «Ничән-че?», «Нинди?» сорауларын аерырга һәм аларга дөрес җавап бирергә өйрәтү.
Тигезлек турында күзаллау формалаштыруны дәвам итү: төрле предмет-лардан торган төркемнәрдә тигез микъдар булуын ачыклау; төркемнәрне санау-исәпләү һәм чагыштыру нигезендә санлы мәгънәләрне дөрес гому-миләштерү (биредә 5 әтәч, 5 курчак, 5 машина — барлык уенчыклар да тигез санда — 5 әр). Кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү (уңда — сулда, өстә — аста, урта-да, почмакта).

**Вакыт буенча ориентлашу.** Балаларда иртә, кич, көн һәм төннең тәүлек тәшкил итүе турында күзаллау булдыру. Конкрет мисалларда төрле вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләргә өйрәтү: элегрәк (башта) нәрсә булды, соңрак (аннары) нәрсә булды; бүген кайсы көн, кичә нинди көн булуын, иртәгә кайсы көн булачагын ачыклау.

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| | II | “5 саны эчендә санау” | 5 саны кысаларында санау күнекмәсен булдыру. |
| | III | “5 кә кадәр санау”. | Балаларны төрле ысуллар белән бишкә кадәр санарга өйрәтү. |
| | IV | “Предметларны чагыштыру”. | балаларны  предметларны озынлыклары буенча чагыштырырга  өйрәтү. |
| | V | “5 саны” | 5 саны эчендә санау күнекмәләрен камилләштерү, предларны озынлыклары буенча чагыштыруны ныгыту, *кичә, бүген, иртәгә* сүзләренең төшенчәләрен аңлауны ачыклау. |
| октябрь | I | “Геометрик фигуралар” | Төрле элементлардан күплек төзергә өйрәтү, таныш булган яссы геометрик фигулар турында белемнәрен ныгыту, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| | II | “6 саны эчендә санау” | 6 саны чикләрендә санау, предметларны озынлыклары буенча чагыштыруны үстерү, таныш булган геометрик фигулар турындагы белемнәрен ныгыту. |
| | III | “7санының килеп чыгышы” | 7 саны эчендә санау, предметларны киңлекләренә карап чагыштыру күнегүләре үтәү, предметларның пространствода урнашу тәртипләрен дөрес атау. |
| | IV | “6 предметны биеклеге буенча чагыштыру” | “Ничә?”, “Ничәнче?”, “Кайсы урында?” дөрес җавап бирергә өйрәтү, предметларны үлчәмнәре арта һәм кими бару тәртибендә урнаштыруны ныгыту, тәүлек вакыты турында белемнәрен камилләштерү. |
| ноябрь | I | “8 саны эчендә санау” | 8 саны эчендә санау, үрнәк буенча предметларны 7 гә кадәр санау күнекмәләрен ныгыту, бирелгән юнәлеш буенча хәрәкәт итүне ныгыту. |
| | II | “9 саны эчендә санау” | 9 саны эчендә санау, геометрик фигуралар турында белемнәрен ныгыту,пространсвода ориентлашырга өйрәнүне дәвам итү. |
| | III | “Предметларны зурлыклары буенча чагыштыру” | Балаларны тәртип саны төшенчәсе белән таныштыру, предметларны биеклекләре буенча чагыштыру осталыгын ныгыту, рәсемнәрдә аерма табу сәләтләрен үстерү. |
| | IV | “10 саны белән таныштыру” | 10 саны белән таныштыру, “Ничә?” соравына дөрес җавап бирергә өйрәтү, тәүлек вакыты турындагы белемнәрен ныгыту, өчпочмак фигурасы турында күзаллауларын камилләштерү. |
| декабрь | | “Вакыт берәмлекләре | Тәүлек өлешләре турында күзаллауларын ныгыту, кәгазь битендә ориентлашуны ныгыту, атна исемнәрен белән таныштыруны дәвам итү. |
| | I | “10га кадәр үрнәк | 10га кадәр үрнәк буенча, кычкырып санау күнекмәләрен ныгыту, бирелгән юнәлеш буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | буенча санау” | хәрәкәт итүне камилләштерү, тирә-юньдә формалары буенча геометрик фигураларга охшаш предметларны табу. |
| | III | | Диагностика |
| | IV | | Диагностика |
| гыйнвар | I | ОББЭ №1 | Мисаллар чишү, пространствода ориентлашу, овал, закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү. |
| | II | ОББЭ №2 | >,< билгеләре, анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр, турыпочмаклык, квадрат, түгәрәк, өчпочмак, тәртип саны. |
| | III | ОББЭ №3 | 1-9 саннары һәм цифрлары, закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү, биек-тәбәнәк, вакытта ориентлашу-атна көннәре, кышның икенче ае *январь* белән танышу |
| | IV | ОББЭ №4 | Тәртип саны, чиктәш саннарны чагыштыру, квадрат, логик мәсьәләләр. |
| февраль | I | ОББЭ №1 | 10 саны, санау таякчыклары ярдәмендә трапеция, көймә төзү, шакмаклы дәфтәрдә эшләү, ике рәсемдә аерымлыклар табу. |
| | II | ОББЭ №2 | 1 дән 10 га кадәр цифрлар, 10 санын ике кечкенә санны кушып табу, закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү, трапеция, квадрат, түгәрәк, өчпочмак. |
| | III | ОББЭ №3 | Мәсьәләләр чишү, санны аңа кагылышлы цифр белән туры китерү, -,+ билгеләре, кышның өченче ае феврал*ь* белән танышу, шакмаклы дәфтәрдә эшләү. |
| | IV | ОББЭ №4 | Кушу һәм алуга мәсьәләләр чишү, тәртип саны, анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр,санау таякчыклары белән эшләү. |
| март | I | ОББЭ №1 | Кушу һәм алуга мисаллар чишү, ике кечкенә санны кушып табу, мәйданда ориентлашу, шакмаклы дәфтәрдә эшләү, түгәрәк, турыпочмаклык. |
| | II | ОББЭ №2 | Предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү, >,< билгеләре, вакытта ориентлашу-атна көннәре, закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү, трапеция, квадрат, түгәрәк, өчпочмак. |
| | III | ОББЭ №3 | Кушу һәм алуга мәсьәләләр чишү, язның беренче ае *март* белән танышу, анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр, дүртпочмаклыклар, алтыпочмаклык. |
| | IV | ОББЭ №4 | Кушу һәм алуга мәсьәләләр чишү, вакытта ориентлашу-тәүлек өлешләре, шакмаклы дәфтәрдә эшләү, өчпочмаклар, “зур”, “кечкенәрәк”, “кечкенә” |
| апрель | I | ОББЭ №1 | Мәсьәләләр чишү, табышмакларга җавап табу, тәртип саны, атна көннәре, ел фасыллары. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | ОББЭ №2 | Математик табышмаклар чишү, 10 санын ике кечкенә санны кушып табу, кәгазь битендә ориентлашу, анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр, түгәрәк, овал, өчпочмак. |
| | III | Диагностика | |
| | IV | Диагностика | |
| май | I | ОББЭ №1 | Мәсьәләләр чишү, язның икенче ае *апрель* белән танышу, закончылыкны табу буенча логик мәсьәләләр чишү, түгәрәк, квадрат, өчпочмак. |
| | II | ОББЭ №2 | Тәртип саны, математик табышмаклар чишү, мәйданда ориентлашу, шакмаклы дәфтәрдә эшләү. |
| | III | ОББЭ №3 | Тәртип саны, 10 санын ике кечкенә санны кушып табу, анализ һәм синтезга логик мәсьәләләр, трапеция, түгәрәк, өчпочмак, предметларны санау таякчыклары ярдәмендә сүрәтләү. |
| | IV | ОББЭ №4 | Мәсьәләләр чишү, язның өченче ае *май* белән танышу, предметларның санын аңа кагылышлы цифр белән туры китерү, март, апрель айлары турында белемнәрне ныгыту, 1 дән 10 га кадәр цифрлар турында шигырьләр. |

## *ПРЕДМЕТЛЫ ТИРӘЛЕК, СОЦИАЛЬ ДӨНЬЯ, ТАБИГАТЬ ДӨНЬЯСЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ*

### *Аңлатма язуы*

«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәмакылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәмбелем бирү бурычларынбилгели.

Балаларга туган як турында мифлар, легендалар, тарихлар сөйләү. Туган шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары, бик күптәнге вакыйгалары, тарихи истәлекләре, музейлары, урамнары белән таныштыру.

Татарстан Республикасының төп символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру. Балаларга үз халкының бер өлеше булуларын аңлату.

Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру. Милли бәйрәмнәр (Нәүрүз бәйрәме,Корбан бәйрәме,Сабантуй,Нардуган һ.б.)турында күзаллаулар булдыру.Башка милләтләргә карата хөрмәт һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү.Милли һәм бөтен дөнья культураларының үткәне һәм бүгенгесе белән танышуга тарту. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күренекле эшлеклеләрнең (шагыйрьләр: Г. Тукай, М. Җәлил, Р. Миңнуллин һ. б., язучылар: А. Алиш, Р. Батулла һ. б., рәссамнар: Х. Якупов, Х. Казаков һ.б., скульптор Б. Урманче һ. б.) тормыш һәм иҗатлары белән таныштыру. Аларның тормышлары һәм эшчәнлекләренә карата кызыксыну уяту.

Балаларның кызыксынуларын исәпкә алып, туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү.

Кешеләрнең табигатьне саклау буенча эшчәнлеге белән таныштыру.Идел-Кама дәүләт тыюлыгы,«Түбән Кама» мили паркы, республиканың табигатен саклауда аларның әһәмияте турында сөйләү.

Тере һәм тере булмаган табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, табигатьтә үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, туган як табигатенә үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен дип карау ярамаганлыгын аңлату, анны файдалануның беренчел күнекмәләрен булдыру («Әгәр мин һәм башка кешеләр дару үләннәрен тамырлары белән җыйса...»).

Туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү. Табигать объектларын үзенчәлекләре буенча классларга һәм төркемнәргә бүләргә өйрәтү (ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, үлән үсемлекләр; урман, болын, бакча үсемлекләре; урман җиләкләре, гөмбәләр, бүлмә үсемлекләре (гөлләре); кыргый һәм йорт хайваннары, кышлаучы һәм күчмә кошлар, балыклар, бөҗәкләр һ. б.).

Республика территориясендәге хайваннарның яшәү рәвешен, аларның тышкы кыяфәт үзенчәлекләрен (гәүдә өлешләре, тәне нәрсә белән капланган), хәрәкәт итү ысулларын (шуыша, оча, йөзә), азыкларын; кайбер бөҗәкләрнең, җир-су хайваннарының, сөйрәлүчеләрнең яшәү мохитенә яраклашуларын күзәтергә өйрәтү. Хайваннарны тавышларыннан танырга булышу.

Туган як табигатенең матурлыгын, аның форма, төс, исләр байлыгын күрә һәм тоя белү күнекмәләрен үстерү.

***Комплексль – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | II | **“**Балалар бакчасы буйлап сәяхәт” | Балаларны бакча белән таныштыруны дәвам итү; балаларбакчасына карата ярату хисе тәрбияләү, баланың максатны аңлый белү сәләтен үстерү, хикәя төзи белергә өйрәнү. |
| | III | “Туган ил кайдан башлана?” | Балаларның туган ил турында күзаллауларын киңәйтү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү, туган илгә кызыксыну формалаштыру**.** |
| | IV | Юл йөрү кагыйдәләре | Юл чаты б-н таныштыру, аның ни өчен алай аталуын аңнарына җиткерү. Танып белүләрен үстерү.Куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәргә кирәклеген аңлату. |
| | V | Бакча тирәли сәяхәт. ”Җәйләр үтте, көзләр җитте.” | Балаларда көзге табигатько соклану сыйфатлары, туган якка мәхәббәт тәрбияләү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү, табигатькә карап соклана белү сыйфатлары формалаштыру. |
| | | “Татарстан – минем Ватаным.” | Татарстан шәһәрләре турында белемнәрен киңәйтү; Ватан турында төшенчә бирү, балаларда горурлык хисе тәрбияләү, Татарстан Республикасында нинди халыклар яшәве турында кыскача мәгълүмат бирү. |
| октябрь | I | “Яшел даруханә” | Тирәлектә үсүче дару үләннәре, аларның кулланылышы, тарихы белән таныштыру; туган җирне ярату, горурлык хисе уяту,белемгә омтылырга, хезмәт сөяргә өйрәтү. |
| | II | “Алтын көз” | Көзнең матурлыгын күрә һәм соклана белүләренә ирешү, балаларда эстетик хис, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык тәрбияләү, сүз байлыгын, диалогик сөйләмне үстерүне дәвам итү. |
| | III | “Икмәк-табын күрке” | Игенче хезмәтенең нәтиҗәсенә соклану хисләре тәрбияләү, балаларда эшлисе килү теләге уяту,ипинең әһәмияте турында төшенчә бирү. |
| | IV | “Милли киемнәр” | Балаларда халкыбызның тарихына карата кызыксыну уяту, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, әби-бабаларыбызның милли киемнәре белән таныштыру. |
| | V | “Ноябрь-көзнең соңгы ае” | Балаларга эстетик тәрбия бирү; күзаллауларын үстерү, сәнгать төрләренә мәхәббәт тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ноябрь | I | “Безнең шәһәр” | Туган илгә, шәһәргә карата хөрмәт хисе тәрбияләү; балаларның шәһәр турында тасвирлама хикәя төзи белүенә ирешү; диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү. |
| | II | “Мәскәү-илебезнең башкаласы” | Туган илебез, аның башкаласына горурлык хисе тәрбияләү, балаларның сөйләм телен үстерү; Мәскәү шәһәре турында белемнәрен киңәйтү. |
| | III | “Иң кадерле кешем-әнием” | Әниләргә, олыларга карата кадер-хөрмәт тәрбияләү; сорауны аңлап, тулы җавап бирүләренә ирешү; шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү. |
| | IV | “Аквариум балыклары” | Аквариум балыкларын ашату, карау вакытында хезмәткә уңай караш тәрбияләү; чагыштыра белү сәләтен үстерү; балыкларның яшәү шартлары турында белем бирү. |
| декабрь | I | “Туган якта кыш” | Кышкы табигатькә хас билгеләр турындагы белемнәрен үстерү, ел фасыллары белән таныштыруны дәвам итү; матурлыкка соклану хисе уяту. |
| | II | “Транспорт төрләре” | Балаларда транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәрбияләү; транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү; фикерләү сәләтен үстерү. |
| | III | “Башкалабыз Казан” | Казан шәһәре турында мәгълүмат бирү; балаларда Ватанга, туган төбәккә, гореф-гадәтләребезгә мәхәббәт тәрбияләү; бәйләнешле сөйләмне, фикерләү сәләтен үстерү. |
| | IV | “Кышкыуеннар” | Балаларның кыш турында белемнәрен киңәйтү; әйләнә-тирәне күзаллауларын ныгыту; өйрәнгәннәрне нәтиҗә ясап сөйли белүләренә ирешү. |
| январь | I | “Су һәм аның үзлекләре” | Тәҗрибәләр үткәрергә өйрәтү; күзәтүчәнлек, фикерләү сәләтен үстерүне дәвам итү; тирә-юньдә күргәннәрдән чыгып нәтиҗә ясый белү күнекмәләре тәрбияләү. |
| | II | “Күрше Чуваш халкы” | Чуваш халкы белән дус-тату яшәү теләге уяту; Чуваш халкының милли киемнәренә, уеннарына соклану хисе тәрбияләү; Чувашия Республикасы символикасы белән таныштыру. |
| | III | “Татарстанның Кызыл китабы” | Балаларга сирәк калган, югалып барган хайваннар, кошлар, үсемлекләр турында мәгълүмат бирү; тыюлыклар турында сөйләү, аларның әһәмиятен аңлату. |
| | IV | “Бүлмә гөлләре” | Балаларда бүлмә гөлләренең матурлыгына соклану тудыру; сакчыл караш аша экологик белем бирү;өлкәннәрдән үрнәк алып гөлләр үстерергә теләк уяту. |
| февраль | I | “Бездә кышлаучы кошлар.” | Кошларга карата шәфкатьлелек тәрбияләү; безнең якларда кышлаучы 4-5 кош белән таныштыру; кош рәсемен ясарга өйрәтү. |
| | II | “Йорт хайваннары һәм кыргый җәнлекләр” | Йорт хайваннарына һәм кыргый җәнлекләргә миһербанлык тәрбияләү; сорауларга аңлы рәвештә җавап бирергә өйрәтү; хайван исемнәрен истә калдыру. |
| | III | “Муса абый” | Муса Җәлил белән таныштыруны дәвам итү; аның сүзләренә язылган җырлар тыңлау; милли горурлык хисе тәрбияләү. |
| | IV | “Кышкы урманга сәяхәт” | Туган җиргә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү; күз алдына китерү сәләтен үстерү; агач исемнәрен ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| март | I | “Яз килде!” | Балаларны яз, аның айлары, билгеләре турында белемнәрен ныгыту; рәсемгә карап кечкенә хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү; табигатькә сак караш тәрбияләү. |
| | II | “Тәҗрибә үткәрү. Суган утырту” | Балаларда суган үстерү теләге тудыру, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү; балаларның логик фикер йөртү күнекмәләрен үстерү; суганның файдалы яшелчә икәне турында төшенчә бирү; суган үстерү турында белемнәрен тулыландыру. |
| | III | “Кошлар-безнең дусларыбыз!” | Кошларга карата мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү; күчмә кошларга ярдәм итәргә кирәклеге турындагы фикерне үстерү; кошлар исемнәрен дөрес әйтергә өйрәтү. |
| | IV | “Нәүрүз бәйрәме һәм “Карга боткасы” | Халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына хөрмәт тәрбияләү; танып белү эшчәнлеген үстерү; милли бәйрәмнәр белән таныштыру. |
| апрель | I | “Сәламәт булу серләре.” | Балаларда чисталык, пөхтәлек тәрбияләү; организмныңны чыныктырырга турындагы фикерне үстерү; кеше тәненең аерым өлешләре турында башлангыч белем бирү. |
| | II | “12 апрель- Космонавтика көне” | Атаклы шәхесләргә ихтирам хисләре тәрбияләү; космос турында башлангыч белем бирү; яңа сүзләр хисабына сзлекләрен баету. |
| | III | “Без яшәгән өйләр.” | Балаларның фикер йөртү сәләтен үстерү; кешеләрнең төрле илләрдә, төрле өйләрдә яшәве турында белем бирү. |
| | IV | “Төрле халыкларның милли ризыклары.” | Балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләү; төрле халыкларның милли ризыклары белән танышу; туганлык турында төшенчә бирү. |
| май | I | “Кеше тормышында чәчәкләр” | Чәчәкләрне саклау теләге уяту; урман һәм бакча чәчәкләрен билгеләре буенча танып, бер-берсеннән аера белергә өйрәтү. |
| | II | “Яшелчә һәм җиләк-җимешләр-витаминнар!” | Җиләк-җимеш, яшелчә төрләрен белергә өйрәтү; аларны үстерүчеләр турында белем бирү; балаларның сөйләм телләрен үстерү, танып белхләрен арттыру. |
| | III | “Сабан туе -дуслык бәйрәме.” | Милли бәйрәмнәр турында белемнәрен үстерү; татар халкының бәйрәмнәренә хөрмәт тәрбияләү; Сабантуй бәйрәменең барлык халыклар өчен дуслык бәйрәме икәнен аңлату. |
| | IV | Чәчәкләр | Җәйге табигаттәге үзгәрешләр белән таныштыруны дәвам итү. Чәчәкләргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |

## 2.3.3. «СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ» белем бирү өлкәсе

***СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ***

***Аңлатма язуы***

Өлкәннәр һәм балалар белән ирекле аралашуны үстерү, тирә-юньдәгеләр белән үзара тәэсир итешүнең конструктив ысулларына һәм чараларына ия булу.

Балаларда сөйләм теленең барлык компонентларын: сөйләмнең грамматик төзелешен, бәйләнешле сөйләмне — аның диалогик һәм монологик формаларын үстерү; сүзлек запасы формалаштыру, сөйләмнең аваз культурасын тәрбияләү,сәнгатьле сөйләм нигезләрен формалаштыру. Тәрбияләнүчеләрнең гамәли рәвештә сөйләм нормаларына ия булуы.

### ***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Шигырь ятлау: М.Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч» | Балаларда балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү. Балаларның хәтер сәләтен үстерү. Шигырьгә кызыксыну уяту һәм ятлау теләге тудыру, һәр эшне вакытында эшләү кирәклеге турында аңлату. |
| | | Рәсем карау һәм хикәя төзү: «Балалар бакчасында» | Тәрбияче хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү,тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү. Тәрбияче биргән план ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү; дусларына һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү. |
| | II | Рәсем карау һәм хикәя төзү: «Балалар бакчасында» | Тәрбияче хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү,тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү. Тәрбияче биргән план ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү; дусларына һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү. |
| | III | Шигырь уку: Р.Рәкыйпов “Мин яратам сине Татарстан” | Балаларда туган илгә карата ярату хисе, игътибарлылык тәрбияләү,тыңлый белү,сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. |
| | | «Башкалабыз – Казан» | Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.Балаларның диалогик сөйләмен, игътибарлылыгын үстерү. Татарстан башкаласы Казан турында белемнәрен тирәнәйтү, Татарстан символикасы һәм аның мәгънәсе белән таныштыру |
| | IV | Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Ә.Бикчәнтәева. «Тәмле сүз» | Балаларга әсәрнең эчтәлегенә төшенергә булышу, матур әдәбият геройлары аша төрле начар сыйфатларга: дорфалык, үзен генә яратучанлыкка карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү.Үзе һәм яшьтәшләре кылган эшләргә дөрес бәя бирә белү, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, монологик сөйләмне үстерү.Проблемалы сораулар аша яхшылык, шәфкатьлелек,дус-лык турында күзаллау бирү |
| | | Өстәл театры. «Өч кыз». Татар халык әкияте | Балаларда якыннарына, әти-әниләренә карата кайгыртучанлык, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.Әкияттәге образларны дөрес итеп бирә белү, хәтер сәләтен үстерү.Әдәби әсәрләр аша тирә-юньдәге вакыйгаларга дөрес бәя бирергә, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | V | «А.Алиш – балалар язучысы» | А.Алиш әсәрләренә кызыксыну уяту, язучы әкиятләре аша балаларда уңай сыйфатлар тәрбияләү.Балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү. А.Алишның тормыш юлын, иҗатын өйрәнүне дәвам итү |
| | | Хикәя уку: А.Алиш. «Каз белән Аккош» | А.Алишның әсәрләренә кызыксыну уяту һәм балаларда сәламәтлекне саклау, ныгыту кебек яхшы сыйфатларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.Әсәрнең эчтәлеген аңларга булышу, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.Балаларның тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кай-таруларына, әсәрнең эчтәлегенә, геройларның эш-гамәленә карата мөнәсәбәтен белдерү һәм аны үз сүзләре белән әйтүләренә ирешү |
| октябрь | I | Бакча тирәли сәяхәт. «Җәйләр үтте, көзләр җитте» | Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлык сыйфатлары тәрбияләү.Үзләштерелгән сүзлек запасына таянып, агач, яфрак, үләннәрне, һава торышын тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен үстерү. Күзәтүләрдән чыгып нәтиҗә ясаганда, исем ясагыч һәм сыйфат дәрәҗәләрен белдерүче кушымчалардан файдаланырга өйрәтү (яшькелт, ямь-яшел, сап-сары, зәп-зәңгәр ). |
| | | Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге табигать» | Балаларда бер-берсен тыңлый белү, кирәк урында тулыландыра белү сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның игътибарлылыгын, рәсемдәге детальләрне күрә алу сәләтен үстерү.Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләргә ярдәм итү |
| | II | Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Көз» | Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияләү. Балаларның хәтер сәләтен, диалогик сөйләмнәрен үстерү.Матур әдәбият белән балаларның кызыксынуын үстерү буенча алдагы эшчәнлектә башлаган эшне дәвам итү, шигырьнең эчтәлеген, катлаулы сүзләрне аңларга булышу, шигырьне яттан сөйләргә өйрәтү. |
| | | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт. «Көзге могҗиза» | Балаларда туган як табигатенә, яшелчәләргә карата сакчыл караш тәрбияләү.Балаларның иҗади күзаллауларын, күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү.Яшелчәләр турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | Сәхнәләштерү: В.Хәйруллина. «Яшелчәләр бәхәсе» | Балаларда матур әдәбият әсәрләренә кызыксыну тәрбияләү.Артистлык сәләтләрен үстерү. Тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту, шигырь эчтәлеген истә калдырырга ярдәм итү. |
| | | Шигырь ятлау: Х.Гарданов. «Түтәлләрдә үсте яшелчә» | Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү. Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын үстерү.Матур әдәбият әсәрен сәнгатьле итеп сөйли белүләренә ирешү, сорауларга тулы җавап алу. |
| | IV | «Игенче хезмәте белән танышу» | Балаларда игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү.Яңа очраган сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету, игенче хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату |
| | | Әңгәмә. «Икмәк – | Икмәккә сак караш тәрбияләү.Балаларның игътибарлылыгын, хәтерен, фикер йөртә белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тормышның нигезе» | сәләтен үстерү.Балаларга икмәкнең әһәмиятен аңлату, ипи үстерүдә катнашучыларның хезмәте турында белемнәрен ныгыту. |
| ноябрь | I | Әкият уку: «Икмәк». Төрекмән халык әкияте | Икмәккә сак караш, хөрмәт тәрбияләү.Балаларның игътибарлылыкларын, хәтер сәләтен, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.Игенче хезмәте турындагы белемнәрен ныгыту, татар халкының хезмәт сөючән халык икәнен, ялкаулыкның бездә элек-электән зур кимчелек, начар сыйфат саналуын, хезмәт сөю һәркемгә хас сыйфат булырга тиеш икәнен аңлату. |
| | | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү: «Безнең гаилә» | Балаларда гаилә әгъзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү.Образлы фикерләү сәләтен үстерү. Балаларның үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзүләренә ирешү. |
| | II | «Әби-бабайларны хөрмәтлик!» | Зурларга карата хөрмәт тәрбияләү. Куелган сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирү осталыгын үстерү.Әби-бабайларның кадерле кешеләр булуын төшендерү. |
| | | Шигырь ятлау: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием» | Гаиләңне ярату, дәү әниләргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү.Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын, диалогик сөйләмен үстерү.Шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирү. |
| | III | «Һәркемнең үз йорты бар» | Балаларда дөньяда яшәүче башка халыкларга ихтирам, алар турында кызыксыну сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның фикерләү, күзаллау сәләтен үстерү.Җир йөзендә яшәүче халыкларның торак йортлары, аларның яшәү урыннарына бәйле булуы турында аңлату. |
| | | Әңгәмә. «Йорт җиһазлары» | Йорт җиһазларына сакчыл караш, аларны ясаучыларга хөрмәт тәрбияләү. Танып белү эшчәнлеген, игътибарлылыкны үстерү.Балаларның йорт җиһазлары турындагы белемнәрен баету, тирәнәйтү. |
| | IV | Шигырь уку: Ә.Ерикәй«Әти йорт төзи» | Балаларда әти кешегә карата ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләү.Балаларның диалогик сөйләмен, логик фикерләү сәләтен үстерү.Шигырьне игътибар белән тыңларга, эчтәлеге буенча тәрбиячененң биргән сорауларына тулы җавап бирергә өйрәтү, балаларның төзүче һөнәре турындагы белемнәрен системалаштыру. |
| | | Савыт-саба кибетенә сәяхәт | Балаларда савыт-сабага карата сакчыл караш тәрбияләү.Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү.Савыт-сабалар кибете турында белемнәрен тулыландыру, тәрбияче үрнәгендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. |
| | V | Чагыштырма хикәя төзү. «Чәйнек белән самавыр» | Балаларда савыт-сабага карата сакчыл караш тәрбияләү.Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү.Савыт-сабалар кибете турында белемнәрен тулыландыру, тәрбияче үрнәгендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. |
| де ка | I | Әңгәмә: «Мин кунак яратам» | Үзеңне әдәпле тоту күнекмәләрен тәрбияләү.Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белүләрен, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирә алу сәләтләрен үстерү.Милли ризыклар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | турындагы белемнәрен тирәнәйтү; балаларны кунакчыл булырга, кунакларга хөрмәт күрсәтергә өйрәтү. |
| | II | Хикәя сөйләү: «Тәлинкәнең төбе нинди?» | Балаларда савыт-сабаларга карата сак караш тәрбияләү.Әсәрнең төп идеясен аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирү күнекмәләрен, монологик сөйләмне үстерү. Алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | Кием-салым кибетенә сәяхәт | Балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү.Тәрбияче биргән соруларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен үстерү.Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү; өс-баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү. |
| | III | Әңгәмә. «Милли киемнәр» | Халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү.Балаларның логик фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү. Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау, төсләрнең берләшүенә игътибар итү. |
| | | «Су һәм кояш – безнең белән гел юлдаш» | Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү. Балаларның үз фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш булдыру. Балаларга сәламәтлекне саклауда табигатьнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру. |
| | IV | Сәхнәләштерү: А.Алиш. «Куян кызы» әкияте | Балаларда матур әдәбиятка кызыксыну, зурлар сүзенә колак сала белү сыйфатлары, сәламәтлеккә сак караш тәрбияләү.Балаларның үзләре белгән әкиятләре буенча тамашалар уйнау осталыкларын, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.Балаларны тирә-юньдәгеләр кыен хәлдә калганын күрә белергә, ярдәмгә килергә, әкият образларын дөрес итеп бирә белергә өйрәтү. |
| | | Шигырь ятлау: Ә.Ерикәй. «Чисталык сөябез» | Шигырь аша балаларда чисталыкка омтылыш тәрбияләү. Эзлекле һәм сәнгатьле итеп шигырьне сөйләү күнекмәләрен, хәтер сәләтен үстерү.Балаларны гигиена кагыйдәләренә гадәтләнергә өйрәтү, чисталык – сәламәтлекнең нигезе икәнен төшендерү. |
| | V | Әңгәмә: «Без суыктан курыкмыйбыз» | Кышкы табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфаты тәрбияләү. Балаларның иҗади күзаллауларын, бәйләнешле сөйләмен үстерү.Кыш турында белемнәрен тирәнәйтү, авазларның дөрес әйтелешен ныгыту. |
| | | Рәсем буенча хикәя төзү: «Кышкы уеннар» | Балаларда үзара дустанә мөнәсәбәт, бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.Балаларның бәйләнешле сөйләм телен, эзлекле итеп сөйли белү сәләтен үстерү.Балаларның хикәя төзеп сөйли белүләрен ныгыту, рәсемнең эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| гыйнвар | I | Хикәя уку: К.Ушинский. «Кыш әбинең шуклыгы» | Серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту.Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү. Кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын ачыклау; балаларны әдәби әсәр аша кышның тасвирланышы белән таныштыру. |
| | II | Балалар бакчасы тирәли экскурсия. «Җимнәр сибәм кошлар | Балаларда кошларга сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.Чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык күнекмәләрен үстерү.Балаларның кошлар турында белемнәрен баету, өлкәннәр ярдәмендә җимлекләр куярга өйрәтү. |
| | | Рәсем карау. «Кошлар килгән җимлеккә» (И.Н.Мурашковска методикасы буенча) | Балаларда кошларга сакчыл караш тәрбияләү, ярдәм итәргә теләк тудыру.Рәсемнең эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга дөрес, ашыкмыйча, башкалар ишетерлек һәм аңларлык итеп җавап бирү күнекмәләрен үстерү. И.Н.Мурашковска методикасы буенча, рәсемгә карап, хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү. |
| | III | Шигырь ятлау: Д.Гарифуллин. «Песнәк» | Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.Шигырьне ятлау теләге булдыру, хәтер сәләтен үстерү.Балаларда шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре булдыру. |
| | IV | Шигырь уку: Г.Лотфи. «Балалар ярдәм итә» | Матур әдәбият аша балаларда мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның диалогик сөйләмен, әйләнә-тирә мохит үзгәрешләрен, аларның бер-берсе белән бәйләнешен күрә белү сәләтен үстерү.Авазларны ныгыту буенча эшне дәвам итү. Балаларның сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүләренә ирешү, кышлаучы кошлар турында белемнәрен ныгыту. |
| | | Төркемдә уен оештыру. «Зоопаркка сәяхәт» | Кыргый хайваннарга карата кайгыртучанлык һәм зоопарк-та үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү.Уеннар һәм тирә-юнь белән танышу барышында балаларның бәйләнешле сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен үстерү.Кыргый хайваннар һәм аларның үзенчәлекләре турында белемнәрен баету. |
| февраль | I | Рәсем буенча хикәя төзү: «Куяннар” | Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.Карау өчен бирелгән рәсем турында сөйлисе килү теләген үстерү.Балаларга хикәя төзеп сөйләүгә булышлык итү, кыргый хайваннар турында белемнәрен тирәнәйтү |
| | II | Әкият уку, сәхнәләштерү. «Төлке белән бүре». Татар халык әкияте | Балаларда театр сәнгатенә мәхәббәт һәм эстетик зәвык тәрбияләү.Балаларның үзләре белгән әкиятләре буенча тамашалар уйнау осталыкларын үстерүне дәвам итү, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.Сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү, әкиятнең эчтәлеген, эзлекле итеп, үз сүзләре белән сөйләргә ярдәм итү. |
| | | Әкият уку. «Бүре аларны нигә ашаган?» Болгар халык әкияте | Балаларда халык авыз иҗатына уңай караш, әкият аша дуслык, бердәмлек сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның үз фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен, хәтерен үстерү. Әкият эчтәлеге буенча сорауларга тулы, аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү. |
| | III | Үз тәҗрибәсеннән чыгып | Балаларда барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хикәя төзү: «Ишегалдында» | тәрбияләү, аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү.Балаларның бәйләнешле сөйләмен, бер-берсен тыңлый, башкаларның җавапларын тулылындыра алу сәләтен үстерү.Рәсемнәр аша балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турындагы күзаллауларын системалаштыру, кешенең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру. |
| | | Рәсем карау. «Песи һәм песи балалары» | Балаларда бер-береңне игътибар белән бүлдермичә, сабыр гына тыңлау сыйфатлары тәрбияләү.Хайваннарның һәм балаларының исемнәрен дөрес атау күнекмәләре бирү, хәрәкәтне белдерә торган сүзләрне ныгыту.Эчтәлекле рәсем буенча хикәя төзергә өйрәтү |
| | IV | Хикәянең эчтәлеген дәвам итеп сөйләү. Г.Мөхәммәтшин. «Ак песи» | Балаларда игътибарлылык, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның иҗади күзаллауларын, фонематик ишетү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.Балаларга үз тәҗрибәләренә таянып хикәя төзергә, үз фикерләрен аңлаешлы итеп башкаларга җиткерергә ярдәм итү. |
| | | «Җир өсте, һава һәм су транспорты» | Балаларда урамда игътибарлылык һәм транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәрбияләү.Транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү.Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү, аларның исемнәрен истә калдыру, кулланылышын белү. |
| март | I | Әңгәмә. «Әни кирәк» | Балаларда әниләргә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү. Балаларның логик фикерләү сәләтләрен, әниләргә карата игътибарлылыкларын үстерү.Сорау – җавап тибында аралашу аша баланы, үз белемнәренә таянып, фикер йөртергә, гомумиләштерергә, аерып карарга һәм берләштерергә өйрәтү. |
| | II | Шигырь ятлау: Н.Гайсин. «Әни гөлләре» | Балаларда шигырьнең тылсымлы юллары аша әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү.Шигырьгә кызыксыну уяту, ятлау теләге тудыру; игътибарлылыкларын, хәтер сәләтен үстерү. Авазларны, сүзләрне ачык әйтеп, сәнгатьле сөйләргә өйрәтү. |
| | III | Рәсем буенча хикәя төзү: «Яз» (И.Н.Мурашковска методикасын кулланып) | Балаларда сөйләгәнне игътибар белән тыңлый белү, сорау-ларга төгәл җавап бирә белү сыйфаты тәрбияләү.Әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру, бәйләнешле сөйләмне үстерү.Балаларны табигатьтә була торган үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү, рәсем буенча сөйли белүләренә ирешү |
| | | Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау | Балаларда бер-берсен игътибар белән тыңлый, иптәше сөйләгәнне тулыландыра, аның эшчәнлегенә дөрес бәя бирә белү сыйфатлары тәрбияләү.Халык авыз иҗаты белән таныштыру аркылы балаларның сүзлек байлыгын, диалогик сөйләмнәрен, хәтер, иҗади уйлау сәләтләрен үстерү.Яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамыш-лар өйрәтүне дәвам итү. |
| | IV | Шигырь ятлау: М.Мазунов. «Яз килә» | Табигатьнең матурлыгын күрә, аңа соклана белү хисләре тәрбияләү.Балаларның хәтерен, сәнгатьле итеп сөйли белү осталыкларын үстерү. Аерым сүзләрне аңларга булышу, татар теленә генә хас авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтүләренә ирешү, шигырьгә кызыксыну уяту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Терәк сораулар буенча, рәсемгә карап, чагыштырма хикәя төзү. «Сыерчык белән карга яз килүгә шатлана» | Кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык хисе тәрбияләү.Балаларның күзаллау, тасвирлый белү сәләтен үстерү. Кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап сыерчыкны һәм карганы танырга өйрәтү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру. |
| | V | Уен-викторина: «Кошлар – безнең дусларыбыз!» | Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.Балаларның күзаллый, тасвирлый белү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен, иҗади мөмкинлекләрен үстерү.Балаларга кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | | Шигырь уку: Г.Тукай. «Карлыгач» | Балаларда кошларга карата сак караш, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү.Әдәби әсәрләргә эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыру, диалогик сөйләмне үстерү.Балаларны игътибар белән шигырь тыңларга өйрәтүне дәвам итү, шигырь аша кошларның үзенчәлекләре турында белемнәрен киңәйтү. |
| апрель | I | Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Ярый әле» | Матур әдәбият аша балаларда саклык, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.Балаларның уй-фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү. Балаларның җөмләләрдәге һәр сүзне үз урынына куеп, кушымчаларны дөрес ялгап әйтә белүләрен камилләштерү. |
| | II | «Планетарийга сәяхәт» уены | Балаларда беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү.Балаларның образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын, хәтерен үстерү.Балаларга Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту. |
| | | Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты | Балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү.Шигырьнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белү, фикерләү, хәтер сәләтен үстерү.Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру,әдәби әсәрләрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү. |
| | III | Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк» | Балаларда Г.Тукай әсәрләренә карата кызыксыну тәрбияләү.Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарлылыгын, иҗадилыкларын үстерү.Балаларда оештыру һәм алып баручы ролен башкару осталыгын формалаштыру, үзләренең эш-гамәлләрен, уенны алып баручы һәм башка катнашучыларның гамәлләренә яраклаштырырга өйрәтү. |
| | | Шигырь ятлау: З.Туфайлова. «Тукай абый» | Шигырьнең тылсымлы сүзләре аша шагыйрьгә карата мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.Балаларның үз теләкләре белән яттан шигырьләр сөйләүгә булган омтылышларын, хәтер сәләтен үстерү.Шигырьдәге төп фикерне әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү |
| | IV | Сугыш ветераннары белән очрашу. «Бөек Җиңү» | 1. Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкны үстерү.Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында балаларның белемнәрен арттыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| май | I | Шигырь уку: Э Шәрифуллина «Минем бабай» | Балаларда патриотик хисләр, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. Шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен үстерү. Балаларның бу шигырь аша Бөек Ватан сугышы геройлары турында күзаллауларын киңәйтү. |
| | II | Уен-викторина. «Чәчәкләр – тормыш яме» | Чәчәкләргә сакчыл караш, туган як табигатен өйрәнү теләге тәрбияләү. Мөстәкыйль фикерләү, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү. Балаларның чәчәкләр турындагы белемнәрен баету, чәчәкләрне танып белергә, тасвирлап сөйләргә өйрәтү. |
| | III | Хикәя уку: Н.Фәттах. «Велосипедлы Мөнир» | Балаларда саранлыкка кире мөнәсәбәт тәрбияләү. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Балаларга хикәя геройларына дөрес бәя бирергә ярдәм итү, каршылыкларны мөстәкыйль рәвештә чишәргә өйрәтү. |
| | IV | Әкият эчтәлеген сөйләү: Ф.Зариф. «Татлы җәй» | Җәйге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксыну хисе тәрбияләү. Балаларның сүзлек запасын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү. Әкиятләргә кызыксыну уяту, сөйли белү теләге тудыру, аңларга өйрәтү. |

## 2.3.4. «СӘНГАТИ - ЭСТЕТИК ҮСЕШ»белем бирү өлкәсе

***ИҖАДИ СӘНГАТЬ***

***Аңлатма язуы***

«Иҗади сәнгать» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үз- үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

***Рәсем ясау***

Балаларның игътибарын табигать матурлыгына юнәлдерү, алар белән берлектә үсемлек һәм хайваннар дөньясы объектларының форма, төс, төзелеш камиллегенә соклану.

Татар декоратив-гамәли сәнгате әсәрләре белән танышуны дәвам итү.

Балаларны «орнамент» төшенчәсе белән таныштыру. Татар орнаментында оста итеп чагылдырылган чын чәчәк-үсемлек мотивларын карау. Бизәкнең өлешләрен аера белергә өйрәтү.

Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: өч яфрак (бер ноктадан өч тапкыр буяу), күкчәчәк, ромашка (акчәчәк), миләш, гөлҗимеш һ. б. ны ясау ысулларын күрсәтү.

Бер, ике яки берничә төсне кулланып, гади элементлардан торган тасма (бордюр) бизәге ясый белүне формалаштыру. Чәчәкле үсемлекләргә төсләрне туры китерү кирәклегенә игътибар итү.

Берничә өлештән (кош, күбәләк, умарта корты фигуралары) торган предметларның формасын һәм төзелешен чагылдырырга өйрәтү.

Төсмерләр (зәңгәрсу, соры, алсу, шәмәхә) белән таныштыру, төсләрне тою хисен үстерү.

Татар декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре буенча күмәк эшләрне үтәүгә тарту.

Туган шәһәр (авыл) тормышыннан матур вакыйгаларны рәсемгә төшерергә теләк уяту. Рәсемнәрне бергәләп карау һәм нәрсә ясаганны

сөйләүләренә ирешү. Иҗади активлык тудырырга булышу.

***Ябыштыру***

Кисеп ябыштыру сәнгатенә кызыксыну уяту, аның эчтәлеген катлауландыра һәм төрле сурәтләү мөмкинлекләрен киңәйтә бару.

Туры сызык буенча башта кыска, аннары озынрак тасмалар кисәргә өйрәтү. Төсле кәгазьдән киселгән тасмалардан предмет сурәтләргә өйрәтү. Сирень, артыш чәһәкләреннән торган композиция төзү өчен, өзек-өзек аппликация техникасы белән таныштыру.

Чәчәкләр, җиләк-җимешләр һ. б. ны ясау өчен, квадраттан түгәрәкләр һәм турыпочмаклыктан оваллар кисәргә күнектерү. Бизәү максатыннан полосада, квадрат, түгәрәктә декоратив бизәкләр төшерергә өйрәтү. Ритм-тоемлау хисен уяту.

Бер бит кәгазьдә берничә предметны кисеп ябыштыру юлы белән (урам, шәһәр), балаларны сюжетлы аппликация төзүгә якын китерү. Пөхтә эшләү күнекмәләре булдыру.

Татар декоратив-гамәли сәнгатенең үрнәкләре буенча әзер формалардан (чәчәкләр, күбәләкләр, кошлар) коллектив композиция төзегәндә, үзара ярдәмләшеп эшләү теләге уяту.

***Әвәләү***

Әвәләп ясау белән кызыксынуны үстерү; балчыктан (тозлы камыр, пластилин) әвәләү күнекмәсен камилләштерү.

Зур кисәктән кечерәк кисәкләр өзеп яки чеметеп алу, аларны бармаклар ярдәмендә түгәрәкләп тәгәрәтү, өлешләрне тоташтыру (чәчәк, гранат, миләш җимешләре); янчелгән шарның өстен шомарту, җиңел генә тарттырып, кырыйларын чеметкәләп чыгу - бөрү (гөбәдия, вак бәлеш һ. б.) күнекмәләре формалаштыру. Махсус таякчык (стека) ярдәмендә ике яки дүрт кисәккә бүлеп (бәлеш кисәкләре), килеп чыккан формаларны үзгәртергә тырышуларын хуплау.

Яңа форма барлыкка китерү өчен, шарның уртасын яньчеп, чокыр ясау ысулын куллану. Махсус таякчыкны файдалану ысуллары белән таныштыру. Әвәләп ясалган әйберләргә шушы таякчык ярдәмендә милли бизәкләр төшерергә омтылуларын хуплау.

Балчык (тозлы камыр, пластилин) белән пөхтә итеп эшләргә күнектерү.

Әвәләп ясалган әйберләрне күмәк композициягә (тәлинкәдәге сый, чәй сервизы һ. б.) берләштерү. Уртак эш нәтиҗәсен күреп шатлану хисләре уяту. Декоратив әвәләп ясауда халык уенчыклары үрнәкләре (Шәмәрдән, Актүбә һ. б. уенчыклар) буенча иң гади образлар тудырырга теләк уяту.

Өстәл театрында куллану өчен, татар халык әкиятләре буенча сюжет әвәләп ясауга кызыксыну һәм теләк тудыру. Балаларда өлкәннәр белән уртак эш нәтиҗәләрен күреп шатлану хисләре уяту.

***Комплекслы – тематик план***

***Рәсем***

| Ай | Атна | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| сентярь | I | Җәй турында картина. | Җәй көнендә алган тәэсирләрен рәсемдә чагылдырырга; төрле агач, куак, чәчәк ясарга; үзенең һәм иптәшләренең рәсемнәрен бәяләргә өйрәтү. Ныгыту:рәсемне битнең билгеле бер өлешенә, яисә бөтен биткә урнаштырырга. Үстерү: -образлы кабул итү, образлы күзаллау;иҗади активлык. |
| | II | Тылсымлы бакчада алтын алмалы алмагач. | Өйрәтү:әкияти образ булдыру; жимеш агачларының җәенке ботакларын чагылдырып агач рәсеме ясарга, рәсемне бөтен биткә урнаштырып ясау. Ныгыту: буяулар белән рәсем ясарга(салфетка белән пумаланы яхшылап кортырга,буяуның кипкәнен көтәргә). Композиция хисен, эстетик кабул итүне үстерергә |
| | | Космея чәчәге. | Үстерү:эстетик кабул итү, төсмерләү хисен. Өйрәтү:космея чәчәге үзенчәлеклген чагылдыру: таҗ һәм яфрак формасы, аларның төсе. Дәвам итү:акварель буяулары, төрле юллар белән эшләүдә күнектерү |
| | III | Чебурашка. | Өйрәтү: яраткан әкият герое образын ясау: Тән формасы: баш һәм башка характерлы үзенчәлекләрен рәсемдә чагылдыру;башта контурны карандаш белән ясарга. Ныгыту: рәсемне пөхтә итеп буяу күнекмәләрен. |
| | | Яулыкны ромашка чәчәге белән бизә. | Өйрәтү:квадратта бизәк төзү(почмак һәм уртасында да),пумаланың очы белән ясау алымын куллану(нокта ясау);буяу белән ясау.Үстерү: эстетик кабул итү, симметрия хисе, композиция хисе. |
| | IV | Көзге урман. | Өйрәтү:көз вакытында алган тәэсирләрен рәсемдә чагылдыру;төрле агачлар ясау;агач, үлән, яфракларны төрлечә ясау. Ныгыту: буяу һәм пумала белән эшләү алымнарын Үстерү:активлык, иҗадилык.Дәвам итү:матур ясалган рәсемнәр гә карап шатлану күнекмәләре формалаштыру. |
| | | Көнбагышлар. | Өйрәтү: көнбагышка хас үзенчәлекләрне пумала һәм мамык таякчык белән ясау.Үстерү: төс тою сәләтен, нәфасәти кабул итү.Буяу белән эшләү күнекмәләрен булдыру. |
| | V | Син күбрәк нәрсә ясарга яратасың? | Өйрәтү: рәсемнең эчтәлеген уйлау; рәсем ясауның төрле ысулларын искә төшерү; үзләренең һәм иптәләренең рәсемнәренә анализ ясау һәм бәя бирү. Тәрбияләү: уйланганны ахырына җиткерергә омтылыш. Иҗадилыкларын үстерү. |
| | | Яшелчәләр уңышы. | Өйрәтү: бер төстәге буяуның төрле төсмерләрен алу өчен, аны су белән сыеклау. Үстерү: төп үрнәк формадан аермаларны курә белүләрен. Табышмак җавапларын табуларына ирешү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| октябрь | I | Яңгыр ява. | Өйрәтү: тирә-юнь тормыштан алган тәэсирләрен рәсемдә образлы чагылдырырга; күренешләрне рәсемдә чагылдырганда белгән алымнар ны кулланырга. Рәсем композициясен төзи белүне ныгыту. Гади графит карандаш, төсле карандашлар белән рәсем ясауда күнектерү.. |
| | | Городец бизәкләре белән таныштыру | Өйрәтү: ачык, халыкчан колоритны, бизәк композициясен билгеләү; төрле элементларны пумала белән ясарга.Үстерү:эстетик кабул итүне, төсмерләү хисен, гүзәллекне тою хисен. |
| | II | Күңелле уенчыклар. | Үстерү: эстетик кабул итүне, образлы күзаллау һәм уйлауны. Агачтан кисеп ясалган богород уенчыклары белән таныштыру.Өйрәтү: халык уенчыкларының сәнгәти ягын билгеләргә;үз теләкләре буенча рәсем өчен материал сайларга. Халык иҗадына кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү. Үстерү:фантазияләүләрен. |
| | | Городец бизәкләре | Үстерү:эстетик кабул итүне, төсмерләү, ритм, композиция хисен. Городец бизәкләре белән таныштыруны дәвам итү. Бизәү элементларын ясарга өйрәтү. Төсләрнең төсмерләрен китереп чыгаруда күнектерү. |
| | III | Дымка бистәсе (авыл). | Үстерү:эстетик кабул итүне, образлы күзаллау, төсмерләү, композиция хисен. Ныгыту:дымка уенчыклары турында белемнәрен, дымка бизәкләрен; халык декоротив сәнгатенә эмоциональ уңай карашларын. Коллективта эшләү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү.Балаларда образлы күзаллау һәм уйлау формалаштыруны дәвам итү. |
| | | Без ничек «Аю һәм бал кортлары» хәрәкәтле уенынуйнадык. | Үстерү:уен эчтәлеген билгеләгән сюжетлы композиция тудыра алуларын.Рәсем ясауның күптөрле алымнарында, төрле материал куллануда күнектерү. |
| | IV | Матур күлмәкле кыз. | Өйрәтү:кеше фигурасын ясарга;кием формасын, форма һәм өлешләрнең урнашуын чагылдырырга, аларны зурлыгы буенча төгәлрәк туры китерү;зур итеп, бөтен биткә ясарга. Карандаш белән ясау һәм буяу алымнарын ныгыту. |
| | | Исәнме, бу- мин! | Өйрәтү:кеше фигурасын ясарга үстерү: үзләренең һәм иптәшләренең рәсемнәрен бәяли белүләрен, предметны һәм аның рәсеменең килеп чыккан нәтиҗәсен чагыштырып, кызыклы чишелешләрне билгеләргә. |
| | V | Автобус. | Транспортның төп өлешләрен урнашу тәртибен рәсем аша җиткерергә өйрәтү.Рәсемне пөхтә итеп буяу осталыгын үстерү |
| ноябр | I | Дидактик уен тудыру «Безгә көз нәрсә алып килде?». | Көз бүләкләре турынд аобразлы күзаллауларын ныгыту.Форма, төс, характерлы үзенчәлекләрен чагылдырып, гөмбә, яшелчә, җимеш ясый алу формалаштыруны дәвам итү. Дидактик уен тудырырга өйрәтү.Уен өчен предметлар тудырыга омтылуларын үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Минем яраткан әкиятем. | Яраткан әкият эпизодының рәсемен ясарга өйрәтү. Иҗадилык, күзаллау үстерү. Эстетик бәя, тудырган әкият образына эстетик караш формалаштыру. |
| | II | Урамнан флаглар белән бизәлгән автобус бара. | Өйрәтү: аерым транспорт төре сурәтләргә; төп өлешнең формасын, детален аларның зурлыгын, урнашуын чагылдырырга; матур итеп бөтен биткә урнаштырырга, зур итеп ясарга; рәсемне буяганда, карандашка төрлечә басым ясап төрле төсмерләр чыгарырга; карандаш белән рәсем ясауны ныгыту. Рәсемне бәяли алуларын үстерү. |
| | | Йөк машинасы. | Өйрәтү:берничә түгәрәк һәм турыпочмаклы өлешләрдән торган предметны сурәтләргә; һәр өлеш формасын, аның характерлы үзенчәлеген бирергә;өлешләрне сурәтләгәндә, аларны дөрес урнаштырырга. Вертикаль һәм горизонталь буйларясау, предметны дөрес бояу күнекмәләрен ныгыту |
| | III | Әкият өйләре. | Өйрәтү: әкитяи өй обрызы тудырырга; рәсемдә аның формасын, төзелешен, өлешләрен чагылдыру. Ныгыту үз теләкләре белән сайлап, төрле таныш материал белән ясый алуларын.<br>Үз рәсемнәрен карау, аларны бәяләү,сурәтне тулыландырырга омтылыш формалаштыру. |
| | | Дымка аты | Өйрәтү: халык декоратив бизәкләр мотивы буенча күләмле әйбер бизәргә; бизәкнең төп элементы, аларның урнашуын ачыкларга. Үстерү: эстетик кабул итүне. Бояу белән ясау алымнарын ныгыту. Үз рәсемнәрен карау, аларны бәяли ала белү формалаштыруны дәвам итү. |
| | IV | Китапка кыстыргыч (городец чәчәге). | Халык сәнгате турында күзаллауларын баетуны дәвам итү. Городец бизәкләре турындагы белемнәрен киңәйтү. Өйрәтү: бизәкләрне буйда урнаштырырга, гуашь белән ясаганда төсләрнең төсмерләрен китереп чыгарырга. Ритм хисе, нәфасәти зәвык үстерү. |
| | | Уйлап ясау | Үз рәсемнәренең эчтәлеген алдан уйлый, уйланганны ахырына җиткерә алуларын үстерү. Акварель белән ясарга өйрәтүне дәвам итү.Образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын үстерү. Үз рәсемнәрен карау, аларны бәяли,уйланышы буенча кызыклы сурәтләрне билгели ала белү формалаштыруны дәвам итү. |
| декабрь | I | “Суык бизәкләр төшергән” | Дулкынлы сызыклар, бормалы-сырмалы бөртекләр, кар бөртекләрен пумала очы белән ясарга өйрәтү; эшчәнлек темасына карата үз хис-тойгыларыңны җиткерә белену ныгыту; дизайнерлык күнекмәләрен үстерү. |
| | II | Кыш. | Картинада кышкы басу, урман, авылны сурәтли, рәсемдә төрле материалларны: гуашь, краска, воск акбурын куллана өйрәнү. Төрле агач, өйләрне ясау күнекмәләрен ныгыту. Иҗадилык, образлы күзаллау күнекмәләрен ныгыту. |
| | | Үзең уйлап эшләү. | Мөстәкыйль рәвештә рәсемнең эчтәлеген, зурлыгын, төсен, кәгазьнең төсен, нәрсә белән ясарга кирәклеген сайларгаөйрәнү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Зур һәм кечкенә чыршылар | Өйрәтү: киң полоскада рәсем урнаштыра, яшь һәм карт агачларны төрле озынлыкта ясый, аларның төсен, үзенчәлекле төзелешен бирә. |
| | | Кар бөртеге | Үстерү: эстетик хисләр,образлы күз алдына китерү, мөстәкыйльлек.Ныгыту: пумаланың очы белән ясау. Үз эшенә бәя бирергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | IV | Кызыл һәм зәңгәр кошлар | Өйрәтү: шигъри образ бирә, тиешле төсне сайлый белүне. Ныгыту:буяу, пумаланы дөрес тоту, Үстерү: образлы,эстетик күзаллауны |
| | | Безнең матур чыршы | Өйрәтү:бизәлгән чыршы аша рәсемдә бәйрәм хисе бирү, палитрада төрле буяуны кушып төрле төсләр табу.Үстерү: образлы күзаллауны, эстетик хисләр. |
| | V | Агач тактада городец бизәкләре. | Өйрәтү:Городец бизәкләре нигезендә шаблон төзү, бизәкнең декоратив элементларын аерып, алардан композиция төзүне. Үстерү: ритм, төс,композиция хисләрен. |
| | | Буйлы- мыеклы | Өйрәтү:- рәсемдә песи образы бирү;төрле сүрәтнең образы сәнгатен. Ныгыту: буяу һәм пумала белән ясау күнекмәләре нигезендә хайваннарны ясау күнекмәләрен. Үстерү: образлы кабул итү, күзаллауны, ясаган сурәттән шатлык, горурлану тудыру. |
| гыйнварь | I | Кыш бабай һәм Кар кызы | Кыш бабайны һәм Кар кызының әкияти образларын сурәтләргә өйрәтү; ясалачак сурәтне кәгазь форматы үлчәменә сыйдыра белү; иҗади эшләүне үстерү. |
| | | Яңа ел бәйрәменең яраткан мизгелләре | Балаларны Яңе ел бәйрәменнән алган тәэсирләрен рәсемдә чагылдырырга өйрәтү; ясалачак сурәтне кәгазь битендә матур итеп урнаштыру; иҗади сәләтләрен үстерү. |
| | II | Балалар кыш көнне урамда уйныйлар. | Кеше сурәтен ясарга өйрәтүне дәвам итү; карандаш белән рәсем ясауны ныгыту; рәсем шөгыленә кызыксыну хисе тәрбияләү. |
| | | Городец бизәкләре. | Городец бизәкләре белән та ныштыруны дәвам итү. Городец бизәкләре төшерергә, краска һәм пумала белән буярга өйрәтү. Ныгыту: рәсем ясау сәнгатен аңлау |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Безнең шәһәр машиналары. | Төрле машиналарны ясарга өйрәтү. Ижадилык үстерү. Турыпочмаклык формасындагы предметларны һәм аларның өлешләре пропорцияләрен, машиналарның характерлы үзенчәлекләрен ясауны ныгыту. Рәсемнәрне карандаш белән ясау һәм буяу күнекмәләрен ныгыгу |
| | | Казлар-аккошлар | Кошларның канат җилпеп очуларын киң буялш аша җиткерергә өйрәтү; пумала белән эшләү күнекмәләрен үстерү; матур әдәбият белән кызыксынуны арттыру. |
| | IV | Хәрәкәтле уен тудыру «Аучылар һәм куяннар?». | Куяннар һәм аучылар турындаобразлы күзаллауларын ныгыту.Форма, төс, характерлы үзенчәлекләрен чагылдырып куян сурәтенясауны ныгыту. Хәрәкәтле уен тудырырга өйрәтү.Уен өчен предметлар тудырыга омтылуларын үстерү. |
| февраль | I | Зоопаркта нәрсә бар? | Хайваннарның гәүдә формаларын рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү; композиция төзү күнекмәләрен ныгыту; рәсемне тулыландырганда иҗади омтылышларны хуплау. |
| | II | Хохлома бизәкләре. | Дулкынлы линияләр, үләннәр, кыска уралмалар ясарга өйрәтү. Пумала очы белән нечкә сызыклар сызу буенча кабатлау. Буйда җимеш һәм яфракларнытигез итеп урнаштыру күнекмәләрен ныгыту. Төс, ритм, композицияне, хохлома бизәкләрен бирү күнекмәләрен ныгыту. |
| | | Солдат постта | Сугышчы образын, костюмы,коралының үзенчәлекләрен рәсемдә бирергә өйрәтү . Сурәтне кәгазь битендә урнаштырырга Рәсемне ясау, буяу кунекмәләрен куллану. Рәсәй армиясенә кызыксыну Һәм хөрмәт уяту, зур итеп ясарга өйрәтү. |
| | III | Бәс белән капланган агачлар. | Эстетик күзаллауны үстерү. Табигатьнең матурлыгын рәсемдә чагылдыруны ныгыту. Карандаш һәм сангина белән ясау күнекмәләрен ныгыту. |
| | | Өч дуңгыз баласының өе | Рәсемдә әкиятнең характерлы билгеләрен бирү, рәсемне дөрес итеп буярга, сангина белән ясарга, сурәтне кәгазь битендә урнаштырырга өйрәнү. Эстетик күзаллауны ныгыту, мөстәкыйль рәвештә сюжет уйлап табарга күнектерү. |
| | IV | Куәтле армиябез | Балаларны махсус транспортларның өлешләрен рәсемдә тасвирларга өйрәтү; үз эшеңә анализ ясау күнекмәсен ныгыту; Ватанны саклаучы хәрбиләргә хөрмәт хисе тәрбияләү. |
| | V | Хохлома подносы | Хохлома бизәкләре элементлары кулланып, түгәрәк кәгазь битендә сурәт ясарга өйрәтү; мамык иаякчыклары белән баскалау ысуллары белән аралаштырып эшләү; нәфасәти кабул итүне үстерү. |
| март | I | Әниләр бәйрәменәрәсем. | Әниләргә бүләк ясау теләге уяту. Зур һәм кечкенә кеше образларын ясый, аларны альбом битенә урнаштырырга өйрәнү.Әниләргә карата хөрмәт, ярату тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | Әнием портреты | Балаларны портрет жанры белән таныштыру; кеше йөзенә хас билгеләрне рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтү.; иң якын кеше Әнигә хөрмәт тәрбияләү. |
| | | Әниемә Городец тактачыгы. | Городец бизәге төшерергә өйрәтү; бизәкләрнең таныш элементларын мөстәкыйль куллануларына ирешү; әниләргә игътибар тәрбияләү. |
| | III | Тәүге чәчәкләр | Рәсем ясаганда төрле сурәтләү материалларын куллана белү; композиция ясау күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү; Балаларны туган якның тәүге чәчәкләре белән таныштыру. |
| | | Төлке һәм куян әкияти буенча рәсем ясау | Балаларның иҗади күзаллауларын үстерүне дәвам итү; әкиятнең төп образларны рәсемдә чагылдырырга өйрәтү; пумала белән төрле ысуллар кулланып эшләү күнекмәләрен ныгыту. |
| | IV | Уйлап рәсем ясау. | Күзаллау, иҗадилык һәм уйлап табу күнекмәләрен ныгыту; үзеңнең эшеңнең эчтәлеген уйлап табарга өйрәтү;башлаган эшне ахыргача бетерергә өйрәтү;гади карандаш, төсле акбурлар белән ясау күнекмәләрен ныгыту. |
| | | Гжель бизәкләре сәнгате белән таныштыру | Аклы-зәңгәрле гжель бизәген бирүне, бизәкнең үзенчәлеген, ритмын, характерын өйрәтү; акварель белән буяуныныгыту; халык сәнгатенә кызыксынутәрбияләү. |
| | V | Үзең теләгән бизәкне яса. | Халык сәнгате стилендә (дымка, хохлома, городец) бизәкләрен бирергә өйрәтү; бизәк төзи, кәгазьнең кирәкле форматын сайлауны ныгыту; эстетик күзаллауны, иҗадилык, халык сәнгатенә хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү. |
| | | Песиле тал ботагы | Песиле тал ботагын натурадан карап ясарга өйрәнү; төрле калынлыктагы пумалаларны куллану күнекмәләрен үстерү; балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерү. |
| апрель | I | Мин әни белән балалар бакчасыннан кайтам. | Рәсем дә әти-әниләр белән очрашу шатлыгын бирә өйрәтү. Зур һәм кечкенә кеше фигураларын бирүне ныгыту.Башта гади карандаш белән ясап, төсле карандаш белән буяу |
| | | Әкияти кош | Гжель бизәкләренең яңа элементларын ясау алымнары белән таныштыру; бизәү күнекмәсен ныгыту; бизәүдә балаларның иҗади активлыкларын, мөстәкыйльлекләрен ныгыту. |
| | II | Киләчәк машиналары | Дөньяда булмаган гаҗәеп машиналар уйлап таптырып, аның төп өлешләрен рәсемгә төшереп, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү; карандашлар белән пөхтә итеп буярга күнектерү; үз рәсемең турында сөйләргә өйрәтү. |
| | | Галәм | Балаларда Галәм киңлекләре һәм күк җисемнәре турында күзаллау булдыру өчен, аларны бергәләп кәгазь битендә ясау; безне чолгап алган дөнья киңлекләре белән кызыксыну тә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Әтәчне бизәү. | Дымка сәнгате буенча ясалган уенчыкны буярга өйрәтү; эстетик кузаллауны, ритмны, корылышны, төсне тою күнекмәләрен иҗадилыкны ныгыту;халык сәнгатенә хөрмәт, уңай эмоциональ чагылыш тәрбияләү: |
| | | Кремльнең ***Спас*** башнясы | Башняны ясау, аның формасын, төзелешен бирә өйрәнү; төрле якларын үлчәү күнекмәләрен ныгыту; карандаш белән беренче форма бирергә күнектерү; туган якка мәхәббәт тәрбияләү |
| | IV | Төзелеш | Балаларга, транспорт хас үзенчәлекләрне рәсемгә төшерергә өйрәтүне дәвам итү; сюжет сурәтләү күнекмәсен ныгыту; балаларны үз рәсемнәре турында сөйләүгә этәрү. |
| | | Натюрморт | Балаларны сурәтләү сәнгате жанрлары белән таныштыру; җиләк-җимешләрне бергә туплап сурәтләргә өйрәтү; балаларны таныш үтенеч сүзләрен кулланырга өйрәтү. |
| май | I | Җиңү салюты | Рәсем төшерүнең төрле алымнарын файдаланырга өйрәтү; төс, форма тоемлау хисен үстерү; Ватанга горурлык хисләре тәрбияләү. |
| | II | Җиңү көне | .Җиңү көне турындагы үз хис-кичерешләрен җиткерә белергә өйрәтү; сурәтне бөтен битне тутырып урнаштыру күнекмәсен үстерү; 9 май көненә карата балаларның ихтирамын көчәйтү. |
| | III | Бакчалар чәчәк ата | Характерлы үзенчәлекләрен биреп, табигатьне сүрәтләү күнекмәләрен, рәсемне бөтен биткә урнаштырырга өйрәтүне дәвам итү;төрле краска белән ясау күнекмәләрен,эстетик, образлы күзаллауныныгыту |
| | | Болында күбәләкләр оча | Рәсемдә әйләнә-тирәне күрсәтеп, катлаулы булмаган сюжетны бирү, рәсемне бөтен биткә урнаштырырга, күзәтүләр нигезендә теге яки бу күренешне тасвирлау, күбәләкләр ясаргаөйрәтү;төсне күзаллауны, эстетик күзаллауны тирә-як табигатьнең матурлыгын күрү күнекмәләрен ныгыту; Туган якка мәхәббәт тәрбияләү |
| | IV | Сирень | Рәсем ясауның гадәти булмаган ысуллары белән таныштыруны дәвам итү; рәсемдә төрлечә эшләү ысулларын бергә үреп бирү күнекмәсен формалаштыру; төрле төсмерлә кулланырга өйрәтү. |
| | | Чебен-Чебенчек, кортлар, бөҗәкләр. | Бөҗәкләр төзелешен рәсемдә күрсәтеп, балаларда күзаллау формалаштыру; төрле материаллар кулланып иҗади сурәтләү сәләтен үстерү; бөҗәкләргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | V | Төсле битләр | Рәсемнең эчтәлеген уйлап, аның эчтәлеген ахырга кадәр дәвам итәргә өйрәтү. буяу белән рәсем ясау күнекмәләрен ныгыту; иҗадилык тәрбияләү. |

***Комплексы – тематик план***
***Кисеп ябыштыру***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | “Аландагы гөмбәләр” | Турыпочмаклыкның почмакларын түгәрәкләп кисәргә өйрәтү; күзаллау сәләтләрен үстерү; гөмбәләргә сакчыл караш тәрбияләү. |
| | II | «Кыяр һәм помидорлар тәлинкәдә ята» | Почмакларын түгәрәкләтеп кисеп, квадрат һәм турыпочмактан овал һәм түгәрәк формасындагы предметлар кисәалуларын дәвам итү;ике кул хәрәкәте координациясен үстерү;эшләрен пөхтә итеп ябыштыра алуларын ныгыту: |
| | III | Вазадагы көзге яфраклар бәйрәме. | Симметрияле формалар кисүнең яңа ысулын өйрәтү; эшләү барышында төрле материалларны яраштыруны ныгыту; көзге төсләргә соклану хисе тәрбияләү. |
| октябрь | II | «Безнең яраткан аюыбыз һәм аның дуслары» | Якынча зурлыгын һәм формасын дөрес чагылдырып, өлешләрдән яраткан уенчык сүрәте тудырырга өйрәтү. Түгәрәк һәм овал формасындагы өлешләрен кисә, сүрәтне пөхтә ябыштыру кәгазь битендә матур итеп урнаштыра алуларын ныгыту. Композицияхисен үстерү |
| | IV | «Песнәкләр» | **С**урәтне өлешләрдән төзергә,агач ботакларын, яфраклар ясап, эшләнмәне тулыландырырга өйрәтүне дәвам итү. Кош гәүдәсе өчен кисеп ясалган өлешләрне дөрес урнаштыру күнекмәсен үстерү. Пөхтә һәм сак эшләргә өйрәтү. |
| ноябрь | II | “Машиналар урамнан баралар” | Төрле машиналарның формасын һәм өлешләренең үзара урнашуын чагылдырырга өйрәтү;түгәрәк буенча, турыга кисүнең күптөрле алымнарын, пөхтә ябыштыру алымын, күмәк композиция тудыра алуларын ныгыту; образлы уйлау, уйлап чыгаруларын үстерү. |
| | IV | “Көзге палас.” | Дөрес кисәргә өйрәтүне дәвам итү. Кайчы белән эшләүне ныгыту; икегә бөкләнгән кәгаздән гади предметлар кисү өстендә эшләү; дөрес төсләр сайлап эшләү; эшләргә бәя бирү. |
| декабрь | II | “Зур һәм кечкенә бокаллар” | Балаларны симметрияле кисү күнекмәләрен, алымнарын өйрәтүне дәвам итү; пөхтә эшләүләренә ирешү; тулы композиция төзүләрен ныгыту. |
| | IV | «Яңа ел белән котлау открыткасы» | Бәйрәм тематикасына туры килгән сурәт белән бәйрәм открыткасы ясарга өйрәнү; кәгазьне берничә өлешкә бөкләп тигез өлешләр,ике өлешкә бөкләп симметрик фигуралар кисә өйрәнүне дәвам итү; кисү һәм ябыштыру күнекмәләрен ныгыту; эстетик кабул итү, образлы күзаллау күнекмәләрен үстерү. |
| январь | II | “Аквариумдагы матур балыклар” | Төсне кабул итү; композиция хисе; барлыкка килгән сүрәтне карау һәм бәяли белүне үстерү; кисү һәм төгәл ябыштыру ысулларын ныгыту. |
| | IV | “Кар бөртекләре” | Үзәк аша берничә кат бөкләнгән кәгазьдән кар бөртекләре кисәргә өйрәтү; балаларның фантазияләрен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| февраль | II | «Пароход» | Элек өйрәнгәннәрне турыпочмаклыкның почмакларын кисү; пароходның башка өлешләрен, төрле формадагы өлешләрне кисеп образлы картина ясарга өйрәтү; гармун кебек бөкләп, бертөрле өлешләрне кисү күнекмәләрен ныгыту; кәгазьдә матур итеп урнаштыру күнекмәләрен ныгыгу |
| | IV | “Күңелле әйлән-бәйлән” | Гармун күрегедәй итеп берничә кат бөкләнгән кәгазьне кисү алымын өйрәтү; материалларга сакчыл мөнәсәбәт тәрбиләү. |
| март | II | “Гөлләрем, чәчәкләрем”. | Үзәк аша берничә кат бөкләнгән кәгазьдән чәчәкләр кисәргә өйрәтүне дәвам итү; чәчәк бәйләме ясап,композиция төзү күнекмәләрен ныгыту; үсемлекләр дөньясы белән кызыксындыру. |
| | IV | “Лаләләр” | Ике төстәге кәгазь алып, бер төсне икенчесе өстенә куеп, чәчәкләр кисәргә өйрәтү; симметрияле кисү алымнарын ныгыту; әйләнә-тирә дөньяны нәфасәти кабул итүләрен үстерү. |
| апрель | I | “Поезд” | Төп өлешне турыпочмаклык формасын кисү, түгәрәкләп почмакларны кисеп алу, берничә өлешкә бөкләп тигез формалар кисү өстендә эшләү. Коллектив белән күнекмәләрен ныгыту |
| | III | “Урман агачлары.” | Төп детальләрнең кисеп ясалган өлгеләре астына кәгазь куеп, астан яктыртып аппликацияләр ясарга өйрәтүне дәвам итү; балаларның туган як үсемлекләре турындагы белемнәрен ныгыту. |
| май | I | “Матур күбәләкләр” | Күләмле композиция төзергә өйрәтү; кайчы белән салмак кисеп, симметрияле формалар ясарга күнектерү. |
| | III | “Табышмаклар” | Образлы күзаллауны иҗадилыкны устерү; төрле геометрик фигурадан туры итеп, диагональ буенча кисеп төрле әйберләрне сурәтләрен ясау буенча эшләү; төгәл итеп кисү, ябыштыру өстендә эшләү. |

***Комплекслы – тематик план***

***Әвәләү***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | II | “Гөмбә.” | Кул һәм бармаклар хәрәкәтен кулланып, предметлар яисә аларның түгәрәк овал, диск формасындагы өлешләрен әвәләү күнекмәләренә өйрәтү; иҗади сәләтләрен үстерү; пөхтәлек, сабырлык тәрбияләү. |
| | IV | Яшелчәләр ( кишер, чөгендер) | Яшелчәләрнең төп билгеләрен( түгәрәк, озынча) күрсәтә белергә өйрәтү. Әвәләү алымнарын ныгыту.Эшләрен бәяләргә өйрәтү. |
| октябрь | I | “Ничек итеп кечкенә Мишутка кәстрүленнән ашалганын күргән.” | әвәләүдә әкияти образ тудыру; бер-берсенә караганда якынча зурлыгын, өлеш формаларын чагылдырып, аю формасы әвәләргә өйрәтү; әкият персонажын сәнгатьле ясауга этәрү;уйлап чыгаруларынүстерү. |
| | III | «Дымково колыны» | Балаларны рус халык иҗат үрнәге-Дымково уенчыгы белән таныштыруны дәвам итү; сыннар |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | әвәләп ясарга өйрәтү; әвәләп ясауның мөһим ысулларын куллануларына ирешү. |
| ноябрь | | “Яраткан уенчыгыңны әвәлә” | Әвәләүдә яраткан уенчык образы тудыруөйрәтү; уч һәм бармаклар белән әвәләүнең күптөрле алымнарын ныгыту; башланган эшне ахырына җиткерергә омтылыш тәрбияләү; үз эшләренә эстетик караш формалаштыру. |
| декабрь | I | “Балалары белән песи.” | Песи һәм песи балаларын әвәләп ясарга өйрәтү; төрле зурлыктагы предметларны әвәләп ясарга һәм аларны гомуми композициягә берләштерергә өйрәтү; ясалачак образ өслеген шомартып, катнаш ысул белән әвәләп ясый белүне ныгыту; йорт хайваннарына мәхәббәт һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | III | “Кар бабай.” | Төрле зурлыктагы түгәрәкләрне әвәләп ясарга һәм аларны гомуми композициягә берләштерергә өйрәтү. |
| | V | “Кышкы тунлы кыз” | Кеше фигурасын гәүдә өлешләрендә кием формасын биреп, пропорцияләрне саклап әвәли өйрәтү; элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. |
| январь | III | «Кар кызы» | Аска табан киңәеп китә торган тун кигән кызны әвәләп ясарга һәм аларны гомуми композициягә берләштерергә өйрәтү; балаларның белгән алымнарын урынлы куллана белүләрен ныгыту, иҗади сәләтләрен үстерү. |
| февраль | I | “Теләгән әйберне ясау.” | Төрле әвәләү алымнары кулланып мөстәкыйль рәвештә эшнең эчтәлеген уйлап әвәләргә өйрәтү; әвәләгән әйберне эчтәлеккә туры килгән әйберләр белән тулылындыру теләге уяту |
| | III | “Эт һәм аның баласы.” | Эт һәм аның баласын әвәләргә өйрәтү; таныш булган әвәләү күнекмәләрен куллануны ныгыту; йорт хайваннарына мәхәббәт һәм сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| март | I | “Чынаяк кирпич”. | Төрле формадагы фигураларны әвәләргә өйрәтүне дәвам итү; чынаякны дөрес әвәләргә өйрәтү; бармаклар белән шомарта белүләрен үстерү; бер-берсенә карата кайгыртучанлык, игътибарлык хисләре тәрбияләү. |
| | III | “Җимлектәге кошлар.” | Кошларны әвәли өйрәнү, төрле зурлыкта сүрәтләү, койрык, канат, башларын дөрес ураштыру; элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. *(Чыпчыклар һәм күгәрченнәр яки каргалар һәм кара каргалар)* |
| | V | “Кувшин.” | Төрле формадагы савыт-сабаларны әвәләргә өйрәтүне дәвам итү; тар муенлы кувшинны дөрес әвәләргә өйрәтү (бербөтен пластилиннан тасма ысулы белән); бармаклар белән шомарта белүләрен үстерү; әниләргә карата кайгыртучанлык, игътибарлык хисләре тәрбияләү. |
| ап ре | II | “Космонавт” | Балаларны дөрес пропорцияләрен күрсәтеп кеше әвәләргә өйрәтүне дәвам итү; скафандр кигән кешене әвәләргә өйрәтү; бармаклар белән шомарта белүләрен үстерү; төрле детальләр белән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | эшне тулыландыру (биялэй, наушник, антенна). |
| | IV | “Тиен чиклэвек ашый.” | Тиенне аңа хас үзенчәлекләрен, торышын биреп әвәләргә өйрәтү; элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. |
| май | II | “Әкияти җәнлекләр” | Балаларны иҗади уйлап әвәли белергә өйрәтү; әвәләү дәвамында элек алган ысулларны куллана белену, иҗади активлыкны үстерү, җәнлекләр турында белемнәрен камилләштерү. |
| | IV | “Кызыл калфак әбисенә күчтәнәч.” | Әкият геройлары образларын ясарга, үз эшеңне һәм иптәшләреңнең эшен бәяләргә өйрәтү; кеше фигурасын күрсәтү, характерлы билгеләрен күрсәтү күнекмәләрен ныгыту; Элек өйрәнгән өлешләрне тоташтыру, тоташкан урыннарны сыпыру күнекмәләрен ныгыту. |

***Җыр***

***Аңлатма язуы***

«Музыка» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә Һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар музыкасына карата кызыксыну уяту, аны тыңларга теләк белдерү. Аның хисле-образлы эчтәлеге турында сөйләү, кичерешләр белән бүлешү.

Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлап, музыканың төп өч жанры: «җыр», «бию», «марш» төшенчәләрен бирү. Балаларның музыка характерын, кәефен бирә белү сәләтләрен үстерү.

Музыка уен кораллары (курай, кубыз, тальян гармун һ. б.) һәм аларның яңгырашы белән танышуны дәвам итү. Татар җырларын дөрес, сәнгатьле итеп һәм аңлап башкарырга, сүзләрен ачык итеп әйтергә күнектерү.

Татар биюенә хас гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «чүгү», «аяк очларында күтәрелү», «берле бишек», «баш-үкчә», «култыклашып әйләнү», «борма» (гади вариант) һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү.

Музыка характерына туры китереп, ритмлы хәрәкәтләр башкаруны формалаштыру.

Хәрәкәтле импровизацияләрдә музыкаль образны чагылдырырга омтылуны хуплау, балалар белән бергә гәүдәләнеш вариантларын («тәкәббер» этәч, «кайгыртучан» тавыклар, тик-тормас чебиләр һ. б.) тикшерү, музыкаль әкият эчтәлеге һәм характерына дөресрәк туры килә торган образны сайларга булышу, һәр иҗади табышны хуплау.

Балалар эшчәнлегенең төрле структурасына музыка өстәү; матур әдәбият, сынлы һәм театр сәнгатьләре әсәрләрен файдаланып, кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә ярдәм итәрлек музыка астында катнаш музыкаль эшчәнлек үткәрү.

## 2.3.5. «ФИЗИК ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе

***Сәламәтлек***

***Аңлатма язуы***

«Сәламәтлек» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру

максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; оешма төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.

Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, тешләрен чистартырга, ашаганнан соң авызны чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга гадәтләндерү.

Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казам пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.

Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк- җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка балаларга элементар ярдәм күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре формалаштыру.

### *ФИЗИК КУЛЬТУРА*

### *Аңлатма язуы*

Гәүдәнең дөрес торышын; хәрәкәтләрне аңлы рәвештә башкару күнекмәләре формалаштыру.Балаларның хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү. Тизлек, көч, чыдамлылык, сыгылмалылыкны үстерү.Терәктән көчле итеп этелеп җиңел йөрү һәм йөгерү күнекмәләрен ныгыту.Тоткарлыклар аша чыгып, куышып йөгерергә өйрәтү. Гимнастика стенкасы буйлап темпны үзгәртеп үрмәләргә өйрәтү.Йөгереп килеп озынлыкка, биеклеккә сикерергә, сикерүнең төренә карап дөрес йөгереп килергә, этелергә һәм җиргә төшәргә, озын сикергеч аша йомшак өслеккә сикерергә, җиргә төшкәндә тигезлек сакларга өйрәтү.Ыргытканда селтәнүне ыргыту белән яраштырырга, тупны бер кул белән ыргытырга һәм тотып алырга, урында һәм атлап барганда аны уң һәм сул кул белән бәреп кире кайтарырга өйрәтү.

Чаңгыда шуыштыру адымы белән йөрергә, сөзәк тауга күтәрелергә, таудан төшәргә, ике көпчәкле велосипедта йөрергә, бер (уң һәм сул) аяк белән этелеп самокатта йөрергә өйрәтү. Тирәлектә ориентлашырга өйрәтү.Спорт уеннары элементларына, ярыш элементлары булган уеннарга, уен-эстафеталарга өйрәтү.

Физик күнегүләр белән шөгыльләнү өчен өлкәннәргә физкультура инвен-таре әзерләргә, аны урынына кире алып куярга булышырга гадәтләндерү.

Балаларның спортның төрле төрләренә карата кызыксынуын хуплау, аларга илнең спорт тормышы вакыйгалары турындагы кайбер мәгълүмат-ларны җиткерү.

Хәрәкәтле уеннар. Балаларны, инициатива һәм иҗадилык күрсәтеп, мөстәкыйль рәвештә таныш уеннар оештырырга өйрәтүне дәвам

итү.Балаларда ярыш элементлары булган уеннарда, уен-эстафеталарда катна-шу теләге тәрбияләү.Спорт уеннарына һәм күнегүләренә өйрәтү.

### *САФ ҺАВАДА ХӘРӘКӘТЛЕ УЕННАР*

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен барышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

### *Комплекслы-тематик план*

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Карусель | Йөгерү күнекмәләрен үстерү, җитезлекне булдыру, сигнал буенча хәрәкәтләрне төгәл башкарырга өйрәтү. |
| | II | Урыныңны тап! | Сигнал буенча хәрәкәтләнергә өйр. Игътибарлылык, җитезлек тәрб. |
| | | Балалар һәм әтәч | Йөгерү күнекмәләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | III | Куышу | Йөгерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйр.хәрәкәтләрне шигырь сүзләренә туры китереп башкару. |
| | IV | Песи һәм тычканнар | Пространствода ориентлашу, бәрелми – төртелми уйнауны булдыру. |
| | | Почмак алыш | Җитезлек, игътибарлылык тәрб. |
| Октябрь | I | Төлке һәм тавыклар | Игътибарлылык тәрб.. Сигнал буенча хәрәкәтләнергә өйр. пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | Мин качам, син тот | Сизгерлек, җитезлек тәрб. Йөгерекклелек күнекмәләрен үстерү.<br>Сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйр.. |
| | II | Яулык | Дус – тату уйнауны булдыру, төгәллек, сизгерлек сыйфатлары тәрбияләү |
| | | Кармак | Ике аякта биеклеккә сикерә белү күнекмәләрен камилләштерү. Игътибарлылык, җитезлек тәрб.. |
| | III | Бау аша сикер | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | Бүре һәм куяннар | Шигырь эчтәлегенә туры китереп, хәрәкәт итәргә өйрәнү, игъбарлылык тәрбияләү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | Почмак алыш | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | Аучы һәм куяннар | Йөгереклелек һәм җитезлек тәрбияләү. Туп ыргыта белү күнекмәләрен үстерү |
| ноябрь | I | Төлке һәм тавыклар | Игътибарлылык тәрб.. Сигнал буенча хәрәкәтләнергә өйр., пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | Балалар һәм әтәч | Җитезлек тәрб., дус- тату уйнарга өйрәтүне дәвам итү. Б-ң физик активлыгын камилләштерү |
| | II | Песи һәм тычканнар | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү күнекмәләре бирү, уен кагыйдәсен саклап уйнарга өйр.. |
| | | Балыклар | Сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйр., күмәк уеннар уйный белү осталыгын үстерү, җитезлек тәрб.. |
| | III | Куяннар һәм төлке | Җаваплылык хисе тәрб., уен кагыйдәсен саклап уйнарга өйр.. Рольләргә бүлешеп уйный белү күнекмәләрен үстерү. |
| | | Чыпчык, чык! | Диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләү. |
| | IV | Мин качам, син тот | Сизгерлек, җитезлек тәрб. Йөгереклелек күнекмәләрен үстерү.<br>Сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәтү |
| | | Кармак | Игътибарлылык, җитезлек тәрб..Ике аякта биеклеккә сикерә белү күнекмәләрен үстерү. |
| декабрь | I | Бау аша сикер | Биеклеккә сикерә белү күнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләү |
| | | Янгын сүндерүчеләр | Сигнал буенча хәрәкәт итә белү күнекмәләрен үстерү. Тиз үрмәләргә өйрәтү. |
| | II | Кем беренче? | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | Машиналар һәм җәяүлеләр | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү, игъбарлылык тәрбияләү |
| | III | Куяннар һәм төлке | Җаваплылык хисе тәрб., уен кагыйдәсен саклап уйнарга өйр. Рольләргә бүлешеп уйный белү күнекмәләрен үстерү. |
| | | Кыршау эченә ыргыт | Билгеле бер урынга, туры китереп, әйбер ыргыта белү күнекмәләрен үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итә белүне дәвам итү. |
| | IV | Балалар һәм әтәч | Җитезлек тәрб., дус- тату уйнарга өйрәтүне дәвам итү. Б-ң физик активлыгын камилләштерү |
| | | Төлке һәм тавыклар | Игътибарлылык тәрб.. Сигнал буенча хәрәкәтләнергә өйр. пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| январь | I | Миңлебай | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | Аксак төлке | Бер аякта сикерү күнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләүне дәвам итү. |
| | II | Энә һәм җеп | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер-бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Кыршау эченә ыргыт | Билгеле бер урынга, туры китереп, әйбер ыргыта белү күнекмәләрен үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итә белүне дәвам итү. |
| | III | Оядагы кошлар | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | Янгын сүндерүчеләр | Сигнал буенча хәрәкәт итә белү күнекмәләрен үстерү. Тиз үрмәләргә өйрәтү. |
| | IV | Чүлмәк сатам | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | Бау аша сикер | Биеклеккә сикерә белү күнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләү. |
| февраль | I | Машиналар һәм җәяүлеләр | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү, игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | Кегляны аудар | Төз ата белү күнекмәсен үстерү, коллективта, уен кагыйдәләренә буйсынып, уйнарга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | Балыклар | Сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйр.әтү, күмәк уеннар уйный белү осталыгын үстерү, сизгерлек тәрбияләү. |
| | III | Ак, димә, кара, димә... | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | Чаналар белән ярыш | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | IV | Соры бүре | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | | Балыклар | Сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйр., күмәк уеннар уйный белү осталыгын үстерү, сизгерлек тәрбияләү. |
| март | I | Парлы эстафета | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | Чаналар белән ярыш | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | II | Буяу сатучы һәм буяулар | Уен кагыйдәләренә буйсынып, уйный белү күнекмәләре тәрбияләүне дәвам итү, хәрәкәт активлыгын үстерү, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |
| | | Каршылыклар юлы | Каршылыкларны җиңә белергә, биремнәрне төгәл үтәргә өйрәнү, тизлек күнекмәләре тәрбияләү. |
| | III | Балыклар | Сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйр., күмәк уеннар уйный белү осталыгын үстерү, җитезлек тәрбияләү. |
| | | Кармак | Игътибарлылык, җитезлек тәрб..Ике аякта биеклеккә сикерә белү күнекмәләрен үстерү. |
| | IV | Буяу сатучы һәм буяулар | Уен кагыйдәләренә буйсынып, уйный белү күнекмәләре тәрбияләүне дәвам итү, хәрәкәт активлыгын үстерү, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |
| | | Йортсыз куян | Җитезлек тәрбияләү, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнү, рольләргә бүленеп уйный белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | күнекмәләрен камилләштерү. |
| апрель | I | Миңлебай | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | Бүре һәм казлар | Җаваплылык хисе тәрбияләү, күмәк уйный белү күнекмәләрен үстерү, үзара килешеп уйнарга өйрәтү. |
| | II | Балыклар | Сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйр., күмәк уеннар уйный белү осталыгын үстерү, сизгерлек тәрбияләү. |
| | | Чилән белән бакалар | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итә, пространствода ориентлаша белү күнекмәләрен үстерү. |
| | III | Флагка кадәр йөгер | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | Тавык кетәклегендә төлке | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менә белү күнекмәләре бирүне дәвам итү. |
| | IV | Әбәк | Игътибарлылыкларын үстерү, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | Парлы эстафета | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| май | I | Каршылыклар юлы | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | Туп югарыга | Туп сикертә белү күнемәләрен үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнүне дәвам итү, күмәк уйный белергә өйр.. |
| | II | Чилән белән бакалар | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итә, пространствода ориентлаша белү күнекмәләрен үстерү. |
| | | Йортсыз куян | Җитезлек тәрбияләү, сигнал буенча хәрәкәт итәргә өйрәнү, рольләргә бүленеп уйный белү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | Чүлмәк сатам | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | Кем тизрәк? | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | IV | Чилән белән бакалар | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итә, пространствода ориентлаша белү күнекмәләрен үстерү. |
| | | Соры бүре | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |

## 2.4 *АТА – АНАЛАР БЕЛӘН ЭШ*

| **Ай** | **Тема** |
|---|---|
| сентябрь | 1. Консультацияләр: “Һәр балада талант бар”, “Балага спорт төре сайлыйбыз”, “Гаилә конфликты һәм балалар”, “Төзү буенча балаларга уеннар”, “Кичке укуның файдасы”.<br>2. Белешмәлек “Әгәр чит илгә барсаң”.<br>3. Газета “Балалар бакчасына рәхим итегез”.<br>4. Ата–аналар җыелышы: «Бала һәм гаилә»<br>- 4-5 яшьлек балаларның психо-физик үсеш үзенчәлекләре<br>- балаларда әхлак нормалары тәрбияләү.<br>5. Табип киңәшләре: “Ваксинопрофилактика”, “Компьютерның һәм телевизорның зыяны”, “Күзләр өчен гимнастика”.<br>6. Әти –әниләрне кызыксындырган сорауларга җавап бирү. |
